# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

2 / 2020



Татар чигеше үрнәкләрендә
озак вакыт дәвамында
кыр һәм бакча чәчәкләре
бәйләмнәре һәм үремнәре
киң таралган булган





**Фәнис ЯРУЛЛИН**

# МОҢ

Һәрбер күңел катлам-катлам,
Һәр күңелдә сер ята.
Күңелдә яткан моңнарны
Гармун тавышы уята.

Уята да алып китә
Үзе белән ияртеп.
Йөздерә уй дәрьясында
Әкрен генә тирбәтеп.

Изри күңел, сафлана җан,
Бетә кайгы-сагышың.
Хуҗа була бар дөньяга
Моң һәм гармун тавышы.

Энҗе яшьләр сытылып чыга
Керфекләр арасыннан.
Моң чәчәкләре ярала
Йөрәкләр ярасыннан.

*1997 ел*

Фоторәсемнәр Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге архивыннан









# Түгәрәк уен

№ 2 2020

16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: А. Р. Мифтахова
Баш мөхәррир: Р. Ә. Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Сөмбелә Вәлиәхмәтова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы: Диләрә Нәүрузова

Альманах 2014 елның 5 августында элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77-58939. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 23.06.2020
Чыгу көне: 30.06.2020

Заказ:
Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:
420021, Казан, Тукай ур., 74а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визарт» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта:** намазлык чигеше фрагменты. XIX гасыр азагы

© «Түгәрәк уен», 2020

*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*

4 Р. Мөхәммәтова
**Алсу Мифтахова: «Милли киемнәребез һәм йолаларыбыз мәдәни код дәрәҗәсендә генә барып җитә ала»**

**ТАССРның 100 еллыгы**

6 Г. Латыйпова
**Егерменче еллар: Гыйльми үзәк тарихы**

**ЙОЛА-БӘЙРӘМ**

10 **Дамир Шәрәфетдинов: «Тарихы гасырларны тоташтыра»**

**ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ**

14 Л. Саттарова
**Татар намазлыгы**

**ӘДӘБИ МИРАС**

22 Л. Мөхәммәтҗанова
**Багучыга барма...** (Татар дастаннарында багучылык һәм фал ачу)

**БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 75 ЕЛ**

25 Е. Шемелова
**Халык җәүһәрләрен кадерләп**

27 Г. Каюмова
**Истәлек кулъяулыгы көч биргән...**

29 Р. Хөсәенова
**Кыр почтасы** (Музыкаль композиция)

**ЭКСПЕДИЦИЯ**

32 А. Борһанова
**Челтәр элдем читәнгә, җилфер-җилфер итәргә...**


















**МИЛЛИ УЕН КОРАЛЛАРЫБЫЗ**

36 Г. Макаров
**Урта гасыр классик татар сәнгате: танбур музыка коралы**

**ХӘТЕР-ХАТИРӘ**

39 Г. Гыйльманов
**Шагыйрь һәм милли бәйрәмнәр**

**ШӘХЕС**

44 Н. Яхина
**Милли музыка сагында**

**БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ**

47 **Җил, яңгыр һәм башкалар**

**БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...**

50 С. Сәмитова
**Уен – халык мәдәниятенең бер күренеше**
(Яңа Чишмә районы Акбүре авылында узган фольклор-этнографик экспедиция материалларыннан)

55 **Балалар иҗаты**

59 **Чигү остасы** (җыр)

**ӨЙ КҮРКЕ – АШ**

60 **Татлы бәлеш**

**ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ**

64 **Шахворд**




# «МИЛЛИ КИЕМНӘРЕБЕЗ ҺӘМ ЙОЛАЛАРЫБЫЗ МӘДӘНИ КОД ДӘРӘҖӘСЕНДӘ ГЕНӘ БАРЫП ҖИТӘ АЛА»

**Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге эшчәнлеге җәмәгатьчелекнең һәм аерым алганда журналистларның игътибар үзәгендә. Театраль тамашачы өчен үзәк «Идел-йорт» фестивале белән кадерле булса, халык музыкасын сөючеләр өчен «Уйнагыз, гармуннар» акциясе, «Түгәрәк уен» фольклор фестивале белән кызыклы. Үзәкнең эше, әлбәттә, фестиваль-бәйрәмнәр үткәрү белән генә чикләнми. Дөресрәге, әлеге һәм башка фестиваль-бәйрәмнәрнең фәнни ягы да бар. Әмма анысы инде үзәкнең «кухнясы». Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры Алсу Мифтахова «Татар-информ»га биргән интервьюсында үзәкнең эшчәнлеге, ягъни «кухнясы» белән таныштырды.**

*– Алсу Равилевна, җитәкче буларак, бүгенге көндә сезнең алга нинди максатлар куелды?*

– Төп максатыбыз – Республикада яшәүче барлык халыкларның матди булмаган мәдәни мирас объектларын популярлаштыру, аларны федераль реестрга кертү. Әлбәттә, без беренче чиратта, алгы планга татар халкының йола-бәйрәмнәрен куябыз.

*– Хәзерге вакытта күпме мәдәни мирас объекты федераль реестрга кертелгән?*

– Бүгенге көндә үзәк тарафыннан 200гә якын объект ачыкланган. Әлегә матди булмаган мәдәни мирас объектларын федераль реестрга кертү буенча берникадәр проблемалар да бар. Узган ел без «Карга боткасы» йоласын федераль реестрга кертә алдык. Ул – Татарстаннан кертелгән беренче объект. Әлеге йола реестрның басма җыентыгында дөнья күрәчәк. Йола-бәйрәмнәрне саклауның бердәнбер юлы – аларны үткәрү, аның төп трансляторлары – мәдәни-күңел ачу оешмалары хезмәткәрләре. Әмма әлегә аларга таянып өчен материал җитми. Һәр объектның паспорты аңлаешлы тел белән язылган, видеофайллар, фотолар беркетелгән булырга тиеш.

*– Татарстанда тагын кайсы объектлар федераль реестрга кертелергә әзер?*

– Быел 14 объектны кертербез, дип торабыз. Алар арасында декоратив-гамәли сәнгать, күн мозаикасы, йолалар, бәетләр, халык авыз иҗатының бүгенге көндә популяр үрнәкләре бар.

*– Болар үзәк белгечләре тарафыннан оештырылган экспедицияләр нәтиҗәсеме?*

– Әйе, татарлар яшәгән һәр төбәкне өйрәнәбез. Фольклор-этнографик экспедицияләр бер төбәктә 50 елга бер тапкыр үткәрелсә, ниндидер йоланың торышын күзалларга мөмкин. Хәзер безгә ашыгырга кирәк. Чөнки йолаларны белгән, хәтерендә саклаган өлкән буын кешеләре дөньядан китә бара. Вакытлар узу белән кайбер йолаларның югалуы да мөмкин. Әмма мин: «Без нәрсәнедер югалтканбыз», – дип, аһ-ваһ килү ягында түгелмен. Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондларында җыелган материаллар күп. Аларны фәнни әйләнешкә генә кертергә кирәк.

*– Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге галимнәре соңгы елларда «Нәүрүз» бәйрәмен актив өйрәнде. Бу бәйрәм көнкүрешебезгә кереп китә алырмы икән?*

– «Нәүрүз» бәйрәме Татарстанда 80 нче еллар азагында торгызыла башлаган. Безнең максат күбрәк юнәлеш бирү булганлыктан – Нәүрүз буенча методик кулланма әзерләдек, семинар үткәрдек. Ул мәдәният хезмәткәрләре куллана алырлык гади тел белән язылган. Кызганыч, быел ул Казанда карантинга бәйле рәвештә үткәрелмичә калды.

*– Милли киемнәрне, милли бәйрәмнәрне халык арасында популярлаштыруның нинди юлларын күрәсез?*

– «Бу безнең тарихыбыз, кулланыгыз», – дип, без һәр ишекне кагып йөри алмыйбыз. Ул традицион бәйрәмнәрдә мәдәни код дәрәҗәсендә генә барлып җитә ала. Мәсәлән, без быел «Алтын хаситә» дизайнерлар конкурсы оештырдык. Анда күпчелеге – татар милли костюмнары. Әйтик, кемдер ул коллекцияләрне интернеттан күрә, ниндидер бизәк аның күңеленә кереп кала. Безнең максат – кешеләргә аларны күрсәтү һәм таныту. Без мөмкинлек тудырсак, кеше үзе сайлап алачак. Моны мәгариф системасы, мәктәп, балалар бакчалары аша да эшләргә мөмкин. Күптән түгел без үзебезнең дизайнерлар ясаган, традицион костюмлы, саф татарча сөйләшә торган 4 мең курчак эшләттек. Моның өчен Татарстан Президенты 6,5 млн сум акча бүлеп бирде. Әлеге курчаклар балалар бакчаларына таратылды. Алар Киров өлкәсендәге уенчыклар фабрикасында эшләнде. Барысы да экологик чиста материалдан ясалды. Алга таба ул курчаклар, фабриканың каталогына кертелеп, сатуга да чыгачак.

*– Алсу Равилевна, үзәкне зур үзгәрешләр көткәнен беләм...*

– Әйе, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге структур үзгәрешләр чорын кичерә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29 февралендәге 154 нче карары нигезендә, Татарстан Мәдәният министрлыгы карамагындагы дүрт дәүләт бюджет учреждениесе берләштерелә. Болар – Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге, Мәдәният һәм сәнгать уку йортлары буенча республика методик үзәге, Татарстан Республикасының халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре үзәге һәм Социомәдәни өлкә һәм сәнгать белгечләренә өстәмә һөнәр белеме бирү (квалификация күтәрү) институты. Оешманың рәсми исеме – Татарстан Республикасы мәдәнияте тармагына инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурслар үзәге. Ресурслар үзәген Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы гамәлгә куя. Штат берәмлеге – 70 кеше.

*– Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Алсу Равилевна. Уңышлар сезгә!*

**Әңгәмәне Рузилә МӨХӘММӘТОВА алып барды**

# Егерменче еллар: Гыйльми үзәк тарихы

**1921 елның декабрендә ТАССРның Халык мәгарифе комиссариаты карамагында Гыйльми үзәк (Академүзәк) барлыкка килә. Комиссариатның фәнни, укыту, мәгариф һәм сәнгати эшчәнлеген алып бару әлеге үзәк вазыйфасына кергән. Биредә республиканың иң яхшы интеллектуаль көчләре фәнни эшчәнлек алып барган. Үзәкнең беренче рәисе математик һәм педагог Гаяз Хисаметдин улы Максудов була. Казанның төп «фәнни һәм мәдәни көчләре» аның кул астына туплана; Татарстан халыклары мәдәниятен үстерү белән бәйле теоретик проблемалар һәм практик чаралар әзерләнә; мәктәпләр өчен яңа дәреслекләр һәм методик кулланмалар төзелә.**



ТАССРның Халык мәгарифе комиссариаты Президиумы. Казан, 1926 еллар. «Казан утлары» журналы архивыннан

Гыйльми үзәкнең гуманитар белем бирү юнәлешен Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте алып бара. Аның бурычы – төбәкне, төбәк халкы тарихын, аерым алганда, татар халкы тарихын өйрәнү. Бирედә Г. Гобәйдуллин, М. Худяков, Р. Фәхретдинов, Һ. Атласи, Н. Фирсов, С. Сингалевич, В. Смолин, Җ. Вәлиди, Г. Шәрәф, Х. Бәдигый, Г. Ибраһимов, А. Сәгъди кебек белгечләр эшләгән. Аеруча Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыятенең беренче секретаре Михаил Худяковның «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» фундаменталь хезмәте зур урын алып тора (1923). Җәмгыять 1924 елдан башлап даими рәвештә татар халкының көнкүрешен, йолаларын, мәдәниятен, этнографиясен, эпиграфик ядкәрләрен өйрәнү һәм сирәк кульъязмаларны җыю максатыннан этнографик экспедицияләр оештыра. Н.И. Воробьев җитәкчелегендә – биш, П. Дульский һәм Г. Рәхим җитәкчелегендә ике экспедиция оештырыла.

Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте гамәлдә булган алты ел эчендә үзен җитди фәнни оешма буларак күрсәтә алган. Мәскәү һәм Ленинград галимнәре дә аның «татар халкының рухи һәм матди мәдәниятен өйрәнү юнәлешендә зур эш алып баруын» билгеләп үткән. Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте татар халкының социаль тарихы, мәдәнияте, көнкүреше мәсьәләләрен комплексы өйрәнүгә, татар теле һәм әдәбиятын, нәшрият эшен өйрәнүгә зур өлеш керткән.

1927 елдан башлап Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте Татар мәдәният йорты составына кергән.

1920 еллардагы иң актуаль проблемаларының берсе – татар телендә фәнни терминологияне булдыру. Шушы елларда татар телендә беренче административ терминнар сүзлеге төзелгән. 1928 елда инде физика, математика, ботаника, туган тел, дәүләт идарәсе, анатомия, физиология, гомуми биология, хокук



**Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең 50 еллыгы. Утырганнар (сулдан уңга): И. Н. Бороздин, Теплоухов, Н. Н. Фирсов, С. А. Пионтковский, М. К. Корбут, Н. З. Векслин, Н. Я. Ежов; басканнар: В. В. Егоров, Н. И. Воробьев, Е. И. Чернышев, П. М. Дульский. Казан, 1929 ел. ТР ДА, 4 тасв., № 20994**



**Ш.Г. Әхмәдиев.**
**ТР ДА, фотодокументлар, инв. № 7849**

фәннәре, җәмгыять белеме, тарих һәм финанс-икътисад фәннәре буенча фәнни терминнар эшләнеп бетә. Барлыгы 9000ләп термин эшләнә.

Халык мәгарифе комиссариатының Гыйльми үзәге башкарган тагын бер зур эш – ТАССРда нәшрият эшен үстерү. Үзәк алдына республиканың милли мәктәпләре өчен төрле фәннәр буенча яңа дәреслекләр төзүче авторлар коллективы булдыру бурычы куела. Дәреслекләр төзү буенча ун коллектив туплана. 1921 ел урталарына йөзләп дәреслек языла һәм татарчага тәрҗемә ителә; туган тел һәм әдәбияты, математика, табигать фәннәре буенча дәреслекләр эшләнә; мәктәп эшчәнлеген оештыру һәм педагогик эшчәнлек буенча методик кулланмалар булдырыла. Шулар арасында беренче һәм икенче баскыч мәктәпләр өчен Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, Г. Худояров һәм башкалар катнашкан авторлар коллективыннан җиде дәреслек; 175 000 данә тираж белән «Татар әлифбасы»ның өч басмасы; И. Сакаев һәм К. Сәгыйтьнең «Табигать белеме» дәреслеге, М. Мөхетдинов, Г. Богданов, Н. Люскинадан математика дәреслеге («Риязият дәресләре»), А.М. Астрябаның геометриясе («Күрсәтмәле Һәндисә»), М. Корбангалиев һәм Ф. Сәйфи-Казанлының географиясе («Табигый җәгъръфия дәреслеге») һәм башкалар. Аерым китаплар 30-40 мең данә тираж белән басылган, 100 мең данә басылганнары да бар.

Шулай да 1920 еллар башында әле Татнаркомпрос барлык милли мәктәпләрне дәреслекләр белән тәэмин итә алмаган, бу нәшрият эшенең матди яктан тиешле дәрәҗәдә тәэмин ителмәгәнлеге белән аңлатыла. «...Нәшрият эше өчен без дәүләт бюджетыннан бернәрсә дә алмыйбыз, икътисад үзәгеннән килгән ярдәм бик кечкенә саннар, – ди халык мәгарифе комиссары Ш.Г. Әхмәдиев. – Ә бит республикадан читтәге татар мәктәпләре дә, Төркестан, Кыргызстан, Башкортстан һәм башка шәркый халыклар да бездән китаплар һәм дәреслекләр көтә».

Кәгазь һәм китаплар бастыру чараларының җитешмәве проблемасы да була. Таткомбинатның эшчәнлеген тикшерү өчен Татсовнархоз төзегән комиссиянең бәяләмәсеннән юллар: «Басу чаралары белән аз тәэмин ителү сәбәпле Таткомбинат Татнаркомпросның Гыйльми үзәге тәкъдим иткән программаны үти алмый – елына 1 751,5 басма бит чыгару мөмкинлеге юк».

1925 елның гыйнварыннан Гыйльми үзәккә җитәкче итеп мәшһүр галим һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Г. Ибраһимов билгеләнә. Аның җитәкчелегендә ТАССРда мәдәният һәм фәннең барлык төп тармакларында диярлек тикшеренүләр башланып китә. Татар дөньясын өйрәнү җәмгыяте һәм Төбәкне өйрәнү бюросының эшен җанландыруны аның төп казанышына кертә алабыз.

1924-1929 елларда Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте тарафыннан тарихи, этнографик һәм лингвистик материаллар җыю максаты белән җиде фәнни экспедиция оештырыла: 1924 елда Н.И. Воробьев җитәкчелегендә экспедиция Арча кантонына чыга, 1925 елда Н.И. Воробьев, К. һәм М. Гобәйдуллиннар һәм С.Г. Вахидов катнашында Мамадыш кантонына комплекслы экспедиция оештырыла, 1926 елда Н.И. Воробьев җитәкләгән экспедиция Кама арты кантоннарында була, 1927 елда Н.И. Воробьев экспедициясе Идел буе районнарын өйрәнә, 1928 елда Г. Рәхим һәм П.М. Дульский катнашындагы экспедиция Арча кантонына чыга, 1929 елда П.М. Дульский Балык Бистәсе кантонын өйрәнә, шул ук елны Н.И. Воробьев һәм Җ. Вәлиди экспеди-

циясе Вотский өлкәсенең Нократ губерниясендә татарлар яшәгән төбәкләрдә була.

Әлеге экспедиция материалларының күп өлеше рус телендә чыгучы «Вестник научного общества татароведения» журналында басылып чыга. Барлыгы 70 фәнни мәкалә һәм 75 рецензия басыла.

Татар дөньясын өйрәнү җәмгыяте язма чыганакларны җыю һәм өйрәнүгә аеруча зур игътибар бирә. Аларны табу өчен җәмгыять әгъзалары республика кантоннарында йөреп кенә калмыйлар, Мәскәү һәм Ленинград архивларында да булалар. 1928 елның октябрендә профессор Н.Н. Фирсов инициативасы белән җәмгыять кысаларында археографик комиссия оештырыла. Аның максаты – архивларда һәм шәхси кулларда таралган татар тарихына караган документларны туплап бастырып чыгару. Комиссия составына С. Бикбулатов (рәис), М. Пинегин, Г. Рәхим, В. Егерев, Е. Чернышев, С. Вахидов, Н. Фирсов, Г. Гобәйдуллин керә.

Күренекле татар галиме, археограф С. Вахидовның эшчәнлеген аерып күрсәтергә мөмкин – ул фәнни экспедицияләрдә бай материал туплый. Казан ханлыгы чорының уникаль тарихи чыганагын – Сәхибгәрәй хан ярлыгын нәкъ менә ул таба, фәнни эшкәртә һәм бастырып чыгара. 1925 елда С. Вахидов Гыйльми үзәк аша ТАССРның Үзәк музеена татар һәм гарәп телләрендә 210 кульъязма тапшыра. 1926 елда галим музейда ачылган шәрыкъ кульъязмалары бүлеген җитәкли. Алдагы елларда С. Вахидов Казанның фәнни учреждениеләре һәм СССР Фәннәр академиясе китапханәләренә өч меңгә якын кульъязма тапшыра. Алар арасында XIV ядкәре булган «Нәһҗ әл-фәрадис» кульъязмаларының өч исемлеге дә була.

1925 елның маенда Гыйльми үзәк карамагында Төбәкне өйрәнү бюросы төзелә. Аның җитәкчесе итеп Г. Ибраһимов билгеләнә. Бюро Татарстанда төбәкне өйрәнү буенча эшчәнлеккә юнәлеш биреп һәм күзәтеп тора, төбәкне өйрәнү конференцияләре уздыра, экскурсия эшен җайга сала, экспедицияләр оештырырга булыша. 1926 ел башына республикада 20дән артык төбәкне өйрәнү оешмасы барлыкка килә. Төбәкне өйрәнү бюросы үз эшчәнлеген җирле фәнни җәмгыятьләр, югары уку йортлары, дәүләт учрежденияләре, шулай ук, СССР Фәннәр Академиясенең Үзәк бюросы белән берлектә алып бара.




ТР ДА, Р-2915 ф., 1 тасв., 3388 эш

1928 елның җәендә Төбәкне өйрәнү бюросы үзгәртелеп, алдына республикада бар яклап тикшеренү эшләре алып бару бурычы куелган Татарстанны өйрәнү җәмгыяте оештырыла. 1929 елның ноябрендә әлеге җәмгыятьнең мәдәният һәм көнкүреш секциясенә Татар дөньясын өйрәнү җәмгыяте дә кертелә. 1928 елдан башлап әлеге ике җәмгыять тә бу өлкәдә эзләнүләр алып барган оешмаларны берләштергән Татар мәдәнияте йорты бүлекчәсе булып тора. 1930 елның мартында Татарстанны өйрәнү җәмгыятенең һәм Татар мәдәнияте йортының вазыйфалары Татар фәнни-тикшеренү икътисади институтына тапшырыла.

Гыйльми үзәкнең гомере озын булмый: эшчәнлеге егерменче еллар азагында кадәр генә бара, 1930 елның язында аның эшчәнлеге туктатыла. Бик күп фәнни, белем бирү һәм төбәкне өйрәнү оешмалары һәм берләшмәләре Гыйльми үзәк язмышына дучар була.

**Гөлназ ЛАТЫЙПОВА,**
**тарих фәннәре кандидаты**

# Дамир Шәрәфетдинов: «ТАРИХЫ ГАСЫРЛАРГА ТОТАША»



**«Беренче совет Сабантуйларын оештыручылар әлеге бәйрәмне татар Олимпиадасы дип атаганнар»**

Совет галимнәреннән беренче булып халык бәйрәмнәрен өйрәнүче Н. Семенов Сабан туен борынгы юнаннардагы Олимпия уеннары белән чагыштыра. Аерым алганда, ул бу хакта менә ничек яза: «Бәлки бу күпләр өчен парадокс булып күренер, ләкин игътибар белән караганда, аларның эчтәлегендә бик якын охшашлык бар. Сабан туе программасы көрәш, йөгереш, ат чабышы, колгага үрмәләү, сикерү, аркан тартышу, халык уеннары кебек физик күнегүләргә нигезләнгән төрле номерлар белән бергә тагын төрле музыкаль, җыр, бию бәйгесе кебек номерлар да керткән. Төрле ярышлар барган мәйдан уртасына нинди дә булса җырчы яки музыкантның үз әсәрләре белән чыгып, бөтен халык игътибарында аларны башкарып, шундук тиешле бәяләмәсен алуын еш күзәтергә мөмкин. Башкаручы шул рәвешле халык белән турыдан-туры аралашкан. Димәк, Сабан туе татарларда физик яктан сәламәтләндерү юнәлешендә генә роль уйнап калмаган, ә эстетик мәгънәдә, ягъни җырны һәм бионе үстерүдә дә әһәмияткә ия булган. Күренә ки, бәйрәм үзенең характеры һәм эчтәлеге күптөрле булуы ягыннан аерылып тора, аңарда гавам күпьяклы эстетик мәнфәгатьләрен, ихтыяҗларын канәгатьләндерү таба алган». Үткән гасырның егерменче елларында беренче совет Сабан туйларын оештыручылар әлеге бәйрәмне татар Олимпиадасы дип атаганнар. Сабан туенда үткәрелә торган көч, чыдамлык, тизлек, җиңеллек буенча сынашлар, күмәк уеннар турында фикер йөртеп, танылган әдибебез Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Н. Фәттах та юнаннарның Олимпия уеннары шулай ук әлеге төр ярышларга карый дигән фикергә килде.

**«Фольклорда билбауга ия булу эпик каһарманның балалыктан яшүсмергә күчү билгесен аңлаткан»**

...Билдән тотып көрәшү (бил алыш) борынгы төрки әдәби әсәрләрдә үк искә алына. Аерым алганда, Йосыф Баласагуниның «Котадгу белек» («Бәхет белеге») дип аталган



дидактик эчтәлекле поэмасында шундый юллар бар: «Әгәр ярашу (килешү) мөмкин булса, яраш, юк икән, сугыш киемнәреңне киен дә бил алышып көрәш».

Шуны ассызыклап үтү зарур: төрки мифологиядә билгә югары семантик статус бирелә. Чөнки ул галәм үзәгенә мөнәсәбәтле гәүдә үзәген чагылдырган кендекнең җисмани аналогиясе буларак карала. Мондый мөнәсәбәт, күрәсең, аны магик үзенчәлекләр белән өрткән. Фольклорда билбауга ия булу эпик каһарманның балалыктан яшүсмергә күчү билгесен аңлаткан. Төрле кораллар белән тулыландырылган әлеге билбау (бил каешы) күчмә торомыш мохитендә сугышчыны белдерә торган мотлак атрибутлардан булган. Шуңа күрә ул төрки дөньяда социаль яктан аерымлану билгеләренең берсен үтәгән. Татар телендә актив кулланыш алган «Билеңне бирмә» гыйбарәсе асылда «Үзеңне җиңдермә; бирешмә» мәгънәсен белдерә.

Батыр образы безнең фольклор, әдәби әсәрләрдә дә яхшы мәгълүм. Шундыйлардан, мәсәлән, «Чура батыр», «Айгали батыр», «Таң батыр», «Зөлкарнәй батыр», «Камыр батыр», «Дутан батыр», «Алпамша» һәм башкалар. Ә менә «Идегәй» дастанында Идегәй үзенең улы Норадын белән бәхәсенә болай ди:



**«Әгәр ярашу (килешү) мөмкин булса, яраш, юк икән, сугыш киемнәреңне киен дә бил алышып көрәш».**



*Гөрелдәсәм, сугар яшенмен,*
*Көлсәм мин бер чуакмын;*
*Киреләнсәм, йокың бозармын,*
*Көрәшсәм, сине егармын.*
*Йөгерсәм, сине узармын.*

Бу әсәрдә, гомумән, Идегәй катнашкан Сабан туе, Җыеннарның күп кенә ярышлары, уеннары тасвирлана. 1380 елда булган Куликовская битва турында язылган рус тарихи чыганаклары аша безгә данлыклы татар батыры Чиләби-Тимер-морза исеме мәгълүм. Х. Шәрифинең 1551 елда язылган «Зафер наме-и Вилайет-и Казан» дигән әсәрендә Казан ханлыгының атаклы һәм бәхетле батырлары дип Нарихи-бәк, Айкилде-бәк һәм Акматай-бәк исемле баһадирлар исемнәре аталган. XVIII гасырда Ашыт алыбы Мәкәләй бине Ак Суфи Сабан туйларында һәм зур Җыеннарда дан тоткан.

XX-XXI йөз башы Сабан туйлары бик күп яңа батырларны билгеләде. Алар шулай ук халыкның календарь бәйрәме мәдәнияте тарихына керәчәк.

**«Борынгы төркиләр күзаллавында тәкә кешеләрне дошман көчләрдән саклау символы булган»**

Сабан туе бәйрәменең көрәш батырына бирелә торган төп бүләк мәсьәләсен тәфсиллерәк ачыклау сорала. Мәгълүм булганча, ул – тәкә.

Этнография, археологик казылма материалларына, язма чыганаклардагы мәгълүматка караганда, борынгы төркиләр күзаллавында тәкә кешеләрне дошман көчләрдән саклау символы булган. Танылган тарихчы Л. Гумилев хезмәтләреннән, татар мифларыннан күренгәнчә, электә ерак бабаларыбыз аеруча маңгаенда ак тамгалы тәкәне кояшка, күккә багышлап корбанга китерә торган булганнар. Безнең фольклор хәзинәбездәге «Алланың кашка тәкәсеме әллә син?» дигән әйтемнең нигезе шуның белән бәйле күрәсең.

Татарларда электә күк тәкәсенә ышану күзәтелгән. Шуңа күрә «Күк тәкә» дип аталган җыен үткәрелүе дә мәгълүм. Бу уңайдан корбанга тәгаенләнгән тәкәгә кул белән орыну гына да ниятләрнең тормышка уңышлы ашуына ышаныч тудырган.

Әйтергә кирәк, кайбер төрки халыкларда хәзерге вакытта иң могтәбәр кунакка пешерелгән тәкә башы тәкъдим итү тәртибе сакланган. Без аның тамырлары ерак тарихларга барып тоташканын XI йөз галиме Мәхмүд Кашгариның мәгълүм хезмәтеннән дә беләбез. Тәкәнең аерым сөякләре магик көч үзенчәлекләренә ия дип тә фаразланган.

Д.Р. Шәрәфетдинов. Татар барда – Сабан туе бар. – Казан, «Гасыр» нәшр., 2003. – Б. 16-82

# ТАТАР НАМАЗЛЫГЫ

**Татар намазлыгы – тукымадан тегелгән, гыйбадәт кылу өчен кулланыла торган чигүле кечкенә келәм. Тарих безгә татар келәмчекләренең тукылган бик борынгы үрнәкләрен сакламаган. Әйтик, төрекләрнең 14 нче йөздәге борынгы намазлык үрнәкләре сакланып калган һәм аларда намазлык бизәү схемасы формалашкан – гыйбадәт келәмендә а́рка булуы һәм аның бизәкләнеп каймалануы, читләрендә бордюрлар булуы шарт.**



Намазлык. XIX гасыр азагы

Татар намазлыгының кабатланмас үз үзенчәлекләре бар – намазлык бизәкләрен өйрәнү шуны дәлилли. Моннан тыш, намазлык татарларның традицион мәдәниятендә дә әһәмиятле роль уйный.

Мөселманнарның биш вакыт намазы, кагыйдә буенча, чиста урында укылырга тиеш – бу урын татар өендә шартлы рәвештә намазлык (фарсы теленнән намаз – көндәлек гыйбадәт дигән сүз) белән билгеләнгән. Төрле төбәкләрдәге традицион татар йортларын сурәтләгәндә, Н.И. Воробьев урта хәлле крестьян өйләрендә дә, бай йортларда да гыйбадәт кылу җәймәләренең стенага һәм матчага эленеп куелуын билгеләп үтә[1]. Шулай итеп, намазлык намаз укуның аерылгысыз атрибуты гына булып калмый, татар өенең бизәге булып та хезмәт итә.

Намазлык композициясенең изге тексты михрабка – мәчет стенасындагы а́ркалы уемга барып тоташа, һәм ул дога кылучыга кыйбланы – Мәккәдәге Кәгъбә юнәлешен күрсәтә. Намазлык бизәге композициясе традицион төстә а́рка үрнәген файдалана (а́рканың эчке җирлеге чигелешсез – буш кала). Келәмнең турыпочмаклы җирлеге өч яктан мул итеп бизәлә, аларда мәңге чәчәкле бакчалар, җәннәт капкалары темасы гаҗәеп үзенчәлекле итеп чагылдырыла. Биредә канәфер, ландыш, төрле кыр чәчәкләре өстенлек итә, чигүле үрнәкләрдә башаклар һәм җиләкләр, чәчәк бөреләре шәйләнә.

Татарстан Республикасы Милли музеенда чигешле намазлыкларның XX гасыр дәвамында тупланган зур коллекциясе саклана. Аларның иң беренче үрнәкләре XIX гасырның икенче яртысына карый, күбесе 19 нчы йөз азагында – 20 нче йөз башында ясалган. XX гасыр урталарында эшләнгәннәре дә бар.

Намазлыкларны җыйнау тарихы да кызыклы. Аларның беренче үрнәкләрен үзенең татар әйберләре коллекциясе өчен Казан коллекционеры һәм француз теле укытучысы Леон Сиклер туплый башлый. 1919 елда коллекцияне Мәскәүгә алып китәләр, бер елдан Шәрык



**Намазлык чигеше детале. XIX гасыр азагы**

халыклары музее төзү өчен зур авырлыклар белән коллекция кире Казанга кайтарыла. 1922 елда әлеге музей тупланмалары Татарстан Республикасының Үзәк музеена кушыла. Л.О. Сиклер коллекциясендәге башка чигү үрнәкләре белән беррәттән, музейга ике борынгы намазлык та килеп эләгә. Шәрык халыклары музее төзү комиссиясе чакыруы буенча, музейга хәлле татар гаиләләре дә кызыклы экспонатлар китерә. Алар арасында Җәмиловадан сатып алынган намазлык та бар – ул башка татар намазлыкларыннан структурасы белән аерылып тора: кабатланып килүче тыгыз бизәк үрнәкләре аны Урта Азия чыганаклары белән бәйли. Коллекциядәге ике борынгы намазлыкның документында «гр. Мангушев һәм Халитовтан» алынган дип күрсәтелгән.

Алга таба намазлыклар коллекциясе 1923 елда Мәскәүнең Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендәге ТАССР павильоны һәм шулай ук 1925 елда Париждагы Бөтендөнья күргәзмәсе өчен профессорлар Николай Воробьев һәм Петр Дульский туплаган үрнәкләр белән тулыландырыла. Шул елларда Татарстан Республикасы Үзәк музеена Арча кантонында яшәүче гаиләләрдән җиде намазлык китерелә. Аннан соңгы елларда республикабызның төрле почмакларында яшәүче татарлар әбиләреннән мирас булып калган, сандыкларда сакланган намазлыкларны музейга китереп тапшыралар. Әлеге экспонатлар сәнгати генә түгел, тарихи кыйммәткә дә ия: һәрберсе татар тормышы тарихын күзалларга мөмкинлек бирә. Алар аша без, тугандаш Урта Азия һәм Урал буе халыкларыныкы кебек үк, намазлыкның кәләш бирнәсенең бер өлешен тәшкил итүен беләбез – кәләш аны чигеп кенә калмаган, җитеннән яки йоннан нигезен дә тукыган.

Төсле ефәк һәм көмеш җепләрдән күпертмәле җөй белән кулдан чигелгән ефәк намазлык Апанаевлар гаиләсендәге бирнәнең бер өлеше булган. Намазлыкның композициясе симметрик һәм төзек, ул өчпочмаклы уемы турыпочмаклы кыса белән уратып алынган михрабны хәтерләтә. Намазлыкның палитрасы нәфис: аксыл шәмәхә җирлектә төсмерләре эзлекле рәвештә алышына барган зәңгәр, сары, шәмәхә, яшел, шулай ук алсу һәм куе шәмәхәгә тартым төсле ефәк җепләр белән чигелгән. Аерым детальләрдә дә, каймаларында да көмеш һәм алтын җепләрнең матур җемелдәве эшләнмәгә затлылык өсти. Чәчәк үремнәренә охшаш өчпочмаклы а́рканың як-якларына тасмалар белән бәйләнгән ике купшы чәчәк бәйләме урнаштырылган. Намазлыкның «михраб уемы» нигезенә гадиерәк алты чәчәк бәйләме чигелгән. Чигүче



Петр Сперанский коллекциясеннән намазлык фрагменты. XIX гасыр азагы

Намазлык чигеше фрагменты. 1925 елда Парижда үткән халыкара күргәзмә өчен тупланган коллекциядән ▶

үрнәкләре чәчәкле а́рканы кабатлаучы кайма чигешендә генә симметриядән бераз читкә киткән.

Бакча һәм кыр чәчәкләреннән торган бәйләмнәр һәм үремнәрнең бераз стильләштерелгән, әмма яхшы танып була торган симметриясез үрнәкләре безгә килеп җиткән намазлыкларның зур булмаган төркеменә хас. Аларны бөгелмәле нечкә сабакларында утырган башаклар, ачылмаган бөреләр һәм үрентеләр бизи, биш-алты төр чәчәктән (канәфер, хризантема, сөмбел һәм башкалар) торган композицияләр нәфислеге белән аерылып тора. Мәсәлән, Касыймнан килгән намазлыкның бизәге шундый. Аксыл-зәңгәр ефәккә кызыл, яшел, шәмәхә, сары, миләүшә, аксыл көрән, ак, көрән һәм башка җепләр белән чигелгән – биредә бер-берсен тулыландыручы унбер төс һәм төсмер бар. Ефәкнең үз җемелдәве өстенә көмеш җепләрнең ялтыравы да өстәлгән.

Татар чигеше үрнәкләрендә озак вакыт дәвамында кыр һәм бакча чәчәкләре бәйләмнәре һәм үремнәре киң таралган булган – ул безнең коллекциянең 19 нчы йөзнең икенче яртысы – 20 нче йөз башындагы намазлыклар бизәле-





Апанаевлар гаиләсе намазлыгыннан чигеш фрагменты

шендә өстенлек итә. Ул чорда чәчәк бәйләме үрнәге госманлы төрекләр чигешендә (сарайнықында да, шәһәр халкында да) дә зур урын алган. Алар татар намазлыклары чигешләренә дә охшап тора[2]. Чигештә чәчәк бәйләмнәренең урнашуында да уртаклык бар – гадәттә ул шахмат тәртибендә яки билгеле бер аралыклар калдырып тезелгән. Төрек чигешенә бу үрнәкләр – чәчәк бәйләмнәре һәм үремнәре Европа сәнгатеннән кергән[3]. Чөнки XVIII гасырдан башлап, Европа илләре белән бәйләнышлар киңәйгәч, Европа сәнгате йогынтысы да арткан. Европа һәм төрек чигешләрендәге чәчәк бәйләмнәренең бер үк техника – күпертмәле җөй белән эшләнүен дә әйтеп үтәргә кирәк. Сәнгать ысулларының уртаклыгы гаҗәп түгел, чөнки татарларның башка илләр белән сәүдә һәм башка элемтәләре иҗади һәм һөнәрчелек карашларына да тәэсир итмичә калмаган. Без сүз алып бара торган намазлыкларның профессиональ осталар тарафыннан эшләнгән булуы бәхәссез, аларның мода журналлары һәм каталоглардагы рәсемнәрне үрнәк итеп алган булуы да ихтимал.



**Намазлык чигеше фрагменты. 1925 елда Парижда үткән халыкара күргәзмә өчен тупланган коллекциядән**

Тагын бер чигеш төркемен аерып күрсәтә алабыз – биредә «бәйләмле» үрнәкләр күзгә симметриясе принцибында башкарылган һәм, чәчәктән бигрәк, зәркән бизәнү әйберләренә тартым стильләштерелгән өч-дүрт формадан тора. Казанда яшәүче Галия Фазлуллина 1966 елда музейга бүләк иткән матур ефәк намазлык шундыйлардан. Аның: «Әнием Гайшә Вәли кызы 1865 елда Байлар Орысы авылында туган. Иске заманда яшәгән булса да, укый-яза белгән һәм кул эшләренә оста булган. Бу әйберләр XIX гасырда аның кулы белән эшләнгән. Пөхтә итеп чигәргә, сугарга һәм кул белән тегәргә бик оста булган», – дигән сүзләре сакланган. Төгәл «михраб төзелешле» намазлык алсу, шәмәхә, зәңгәр, ачык яшел һәм сары төсләр өстенлек иткән нәфис чигеш белән бизәлгән. Биредә, алдагы мисаллардагы кебек үк, оста сайланган дистәдән артык төсмерне табарга була. Намазлык а́ркасы нигезендәге чәчәк бәйләмнәре өч стильләштерелгән яфрактан торган вазадан «үсеп чыга». Чәчәк һәм яфракларның яңача бирелеше аларны табигый прототипларыннан шактый ераклаштырган. Шул ук сыйфатларны – композицияләрнең симметриясен, стильләштерелгән чәчәк үрнәкләренең шартлылыгын – музейга 1982 елда театр рәссамы Петр Тимофеевич Сперанский (1891-1964) коллекциясеннән кергән намазлык бизәкләрендә дә күрергә була. Рәссамның халык сәнгате әйберләрен туплап кына калмыйча, татар бизәген тирәнтен белүе һәм өйрәнүе дә билгеле[4]. Бу стильгә охшаш ефәк намазлык Россия этнографик музеенда да саклана – аның тарихчы һәм этнограф, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы Гайнетдин Әхмәров (1864-1911) тупланмаларыннан булуы игътибарга лаек[5]. Ике намазлыкның охшашлыгы Сперанский коллекциясендәге намазлыкның 19 нчы йөз азагында эшләнгән булуын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Музей коллекциясе мисаллары кул эше осталарының чигелә торган тукыманың төсенә һәм фактурасына зур игътибар бирүләрен күрсәтә. Ул чорда зәңгәр, шәмәхә, куе сары төсле купшы ефәк, шулай ук, куе караңгы төсмерле һәм кара кәшимир, постау, сатин тукымалар өстенлек иткән. Куе төсле ефәктә чигеш аеруча купшы, бәйрәмчә күрен-



**Намазлык чигеше фрагменты. XIX гасырның соңгы чиреге**

гән, кыйммәтен арттырган. Намазлык тукымасы төсенә җепләр төсе дә тәңгәл китереп сайланган. Палитраның һәр төсе ачык һәм «яңгыравыклы» булса да, башка төсләр арасында ул «кычкырып тормыйча» гамманың бер өлешенә әйләнгән.

Чигүле намазлыклар өчен ак тукыма сирәк алынган, әмма башка ачык төсләрдән эшләнгәннәре дә бар. Келәмчекләрнең ачык төстәге йон җепләр белән чигелгәне игътибарны җәлеп итә. Ул музейга 1976 елда Чирмешән районы Каргалы авылыннан бүләк ителгән. Бүләк итүче ханым намазлыкның 1920 елда сатып алганлыгын әйткән. Әлеге намазлык кул эше осталарының әзер схемалар һәм гадәти үрнәкләр белән гаҗәеп иркен эш итүләрен күрсәтә. Чигүче S рәвешендәге сызыклардан торган чылбырлы а́рка силуэтын җайлы гына үзгәртә алган. Бормаларга әкәмәт фигуралар урнаштырган: алар бер үк вакытта кояшны да, ачылган чәчәк таҗын да, «дөнья куласасы»н дә хәтерләтә. Намазлык тукымасына әлеге эре бизәкләр шулкадәр тыгыз чигелгән – ул Урта Азия келәмен хәтерләтә. Намазлык бизәкләрендә җирле халыкның үз сәнгате үрнәкләре (яфраклы үрентеләр, вак чәчәкләр) Урта Азия чигешенә хас бизәкләр бергә аралаштырылган. Чигеш төсләре дога кылучының тормышында рухи һәм фани дөньяның аерылгысызлыгын символлаштыра.

Намазлык орнаментларында татар чигеше сәнгатенең борынгы тамырлары, кул эше осталарының вакыт таләбен тоемлавы һәм күрше халыклар белән мәдәни бәйләнешләр чагыла. Декоратив схеманың тотрыклыгына һәм бизәкләрнең кабатланышына карамастан, намазлыкларның бизәлеше татар чигеше тарихында үзенең зур урынын алып тора.

**Лилия САТТАРОВА,**
**сәнгать белгече, Татарстан Республикасы**
**Милли музееның тупланмалар буенча**
**җаваплы генераль директор урынбасары**

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасы Милли музееннан

[1] Воробьев Н.И. Казан татарлары. (Халыкның Октябрьга кадәрге чордагы материаль культурасын этнографик тикшерү). – Казан: Татгосиздат, 1953. – Б. 193-195.
[2] Dietrich B. Kleinasiatische Stickereien. Plauen: Dietrichs Selbstverlag, 1911. Abbildung 8, 9; S. 47, 51.
[3] Sürür, Ayten. Türk işleme sanatı. – İstanbul, 1976. – S. 47.
[4] Сперанский П.Т. Татарский народный орнамент. – Казань: Татгосиздат, 1948.
[5] Традиционная культура татар XIX-XX веков. Каталог выставки. – Санкт-Петербург, 2012. – С. 146.

# Бергәләп бизибез!



# БАГУЧЫГА БАРМА…

## (ТАТАР ДАСТАННАРЫНДА БАГУЧЫЛЫК ҺӘМ ФАЛ АЧУ)

Исламда багучылык ширек гамәл санала. «Ширек» – гарәп сүзе, «күп аллага ышану», «мәҗүсилек», «Аллаһыга иптәш булдыру» дигән мәгънәләргә ия. Аллаһының иптәшкә һичбер мохтаҗлыгы юк, шуңа күрә исламда ширек – иң зур гөнаһ һәм аның һәртөрле формасы тыела. «Багучыга барма, башыңа кайгы алма», «Күрәзәчегә барсаң, кырык көн буена намазың кабул булмас» кебек тыюларның нигезендә юрау, багу, күрәзәлек итү кебек гамәлләрнең динебездә һич кенә дә хупланмавы ята. Әмма халыкта киләчәккә күз салу теләге, язмыш белән кызыксыну элек-электән гаять көчле булган. Борынгы төркиләрнең IX гасырда ук рун язулы атаклы «Ырк битиг» дип аталган юрау китабы төзегәнлекләре мәгълүм. Китап зур практик әһәмияткә ия булган. Шушы һәм башка чыганаклар нигезендә соңрак халыкта төш юрау китапларының таралуын да багучылыкның үзенчәлекле бер тармагы буларак карарга мөмкин.

Чыннан да, ислам кануннарына туры килмәсә дә, халыкта багучылык, язмыш юрау, күрәзәчелекнең хикмәтле гамәлләрдән саналуын һәм аңа мөрәҗәгатьнең күплеген инкарь итеп булмый. Киләчәк тормышта ниләр булачагыннан алдан ук хәбәрдар булу белән бәйле шөгыль халыкта ислам ныгып урнашкач та дәвам иткән. «Фал ачу», «Коръән ачу», «китап ачу», «палтар ачу»ларның татарлар арасында киң таралган булуы шуны раслый. Мөселманнарда багучылыкны изге китап Коръән белән бәйләү күренеше барлыкка килгән. Бу күренешне исламгача ук ныгып урнашкан



**ТФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган гарәп язулы татар эпик текстлары (рәсемдә – «Каһарман Катил» дини-героик китаби дастаны, 39 колл., 6121 сакл. бер.) фалчылык турында күп нәрсә сөйли ала… Рәсемдә – филология фәннәре докторы Л.Х. Мөхәммәтҗанова.** Илсөяр ЗАКИРОВА фоторәсеме



**ТФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган гарәп язулы татар эпосы – дастаннар. «Йосыф китабы», «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Буз егет», «Каһарман Катил», «Чура батыр» һәм башкалар – сюжетына борынгы багучылык элементларын тирән сеңдергән фольклор ядкарьләре**

борынгы традицияләрнең гаять көчле булуы белән аңлатырга мөмкин. Исламда тыелган булуына карамастан, багучылыкның халыкта шул ук ислам тәртипләре кысасына кертеп карала башлавы бик кызыклы. Гомумән, фәндә «мөселман магиясе» дигән күренешнең барлыгы да мәгълүм. Бу – Коръән хәрефләре, сүзләре һәм Коръәндәге исемнәргә карап юрау, күрәзәлек итүдә текст мәгънәсен файдалану, Коръән сүрәләрен талисман-бөти сыйфатында файдалану һ.б.

Астрологларга мөрәҗәгать итеп яки башка рәвештә багучылык белән шөгыльләнүгә, каһарман язмышын багып, алдан белүнең кызыклы нәтиҗәләренә күпләгән мисаллар татар дастаннарында да теркәлеп калган. Димәк, фал ачу, фал китабына, фалчыга мөрәҗәгать татар халкында бик популяр булган. Аллаһыны узып, киләчәккә күз ташлаудан аермалы буларак, теге я бу мәсьәләдә изге Коръәнгә, китапка карап, Аллаһ язганны алдан белү гадәте – борынгыдан килгән багучылыкны исламга нигезләп алып барырга тырышу нәтиҗәсе булса кирәк. Китапка изгеләштереп карарга күнеккән татар халкында шушы ук максатларда еш кына язма әдәби истәлекләргә дә мөрәҗәгать итү очрый. Мәсәлән, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабын фал ачу өчен куллану очраклары мәгълүм.

Татарларда XVIII гасырдан шактый киң таралган «Каһарман Катил» дастанында да әлеге борынгы традиция, ягъни киләчәкне юрау максатыннан төрле магик ысулларга (аларның гарәпчә исеме – «гыйлем әл-гайб», ягъни «яшерен белем») мөрәҗәгать итү шактый әһәмиятле урын алып тора. Игътибар итсәк, бу әсәрнең жанры – дини-героик эпос, төп темасы – батырлык, ислам өчен көрәш. Шулай булуга карамастан, әсәрдә багучылык, фал ачу бик популяр сюжет сызыгын тәшкил итә.

Әсәрнең башында ук, кинәт пәйда булган кара болыт, яшен һәм караңгылык фонында өч яшьлек Каһарманның серле югалуына бик кайгырып, атасы – падишаһ Таһмасып багучылар җыя. Югалган баласы хәсрәтеннән вафат булган Таһмасыпның хамилә (йөкле) калган хатыннарыннан берсе бала тапкач, Таһмасып урынына падишаһ булган Һирасып баланың «бәхетен, киләчәген карар өчен» багучыларны җыя. Беренче очракта багучылар



китап белән эш йөртсәләр, ягъни киләчәк язмыш хакында кирәкле мәгълүматны китап ачып белсәләр, икенче очрактагылары – мөнәҗжимнәр, ягъни астрологлар – юрауны йолдызларга карап башкара. Шунысы да бар: фалчы-багучылар сүзе, урыны-вакыты җиткәч, һичшиксез тормышка аша. Бу очракта да Каһарманның һәм ул югалгач туган бәрадәре (бертуганы) Каһтаранның язмышлары юраучылар әйткән финишка һич үзгәрүсез барып ялгана.

Үзеннән соң ил белән Һушән шаһ исемле падишаһ идарә итәчәген, шаһзадәләр Каһарман белән Каһтаранның аңа тугрылыклы хезмәттә булып, зур батырлыклар кылачагын да Һирасып мөнәҗимнәр чакыртып алдан белә, шул ук вакытта ул моның Аллаһ биргән язмыш булуы белән килешә, багу аша беленгән мәгълүматка Аллаһ сүзе итеп карый, «Ходайның һичбер эшенә каршы килергә мөмкин түгел» дип, багучылар әйткәнгә карусыз ышана. Алай гына да түгел, багучылар юраганны тормышка ашыру өчен үзе үк чаралар да күрә – алар әйткәнгә туры китереп, Һушән шаһ чит мәмләкәттән тәхеткә чакыртып китерелә, улы Каһтаранга, «Баһадирлык падишаһлыктан артык», дип, падишаһка карусыз тугрылыклы хезмәт итәргә, бертуганы Таһмасыпның улы баһадир Каһарманга юлыкканнан соң аңа кадер-хөрмәт күрсәтергә вәгазь-нәсихәтен әйтә. Монда да, алдарак әйтелгәнчә, күрәзәчеләр юраган гел юш килеп тора, ә Каһтаран исә атасы әйткәннәрне төгәллек белән үти. Дастанда багучы-астрологларның киләчәкне «китапларына карап», «китап ачып» әйтеп бирүләре – бик үзенчәлекле күренеш.

Каһарман язмышын алдан күрүгә мисалны Алтын Урда составында яшәгән татар һәм кайбер башка төркиләр иҗатында киң таралган «Чура батыр» дастанында да очратабыз. Биредә татар батыры Чураның үлеме нидән икәнен белер өчен урыслар, астрологларны җыеп, аларга мөрәҗәгать итә. Болай эшләү борынгы, хәтта урта гасырлар урыс мәдәнияте өчен дә хас нәрсә түгел. Чурага багышланган дастаннарның татар версиясенә килеп кергән әлеге сюжет урта гасырлар Көнчыгыш, шул исәптән төрки әдәбиятларда һәм халык иҗатында исә еш күзгә чалына. Багу төрләреннән биредә киләчәкне йолдызларга карап билгеләү укымышлы татарларда таралыш алган дастанга Көнчыгыш әдәбияты тәэсире булырга мөмкин.

«Таһир-Зөһрә» сюжетлы дастаннарның татар вариантларында да багу элементлары бик күп. Сайади вариантында каһарманнар язмышын төш күрү аша юрау очрый, ә Кормаши вариантында падишаһка да, аның вәзиренә дә һәр икесенең ниятләре тормышка ашачагы турында багучылык белән шөгыльләнүче дәрвиш хәбәр итә һ.б.

Татарларның бу һәм биредә телгә алынмаган башка дастаннарында төрки эпоска хас мондый сюжет-мотивлар, детальләр урын алып тора. Күрәсең, күрәзәлек итү, язмышны алдан белү теләге – халык тормышының табигый атрибутлары.

Күргәнебезчә, дастаннарыбызда төрле традицияләр күп кенә очракта бер-берсенә җиңел яраша. Тарихи-героик «Чура батыр»да да, ислам җиңүен сурәтләгән дини-героик «Каһарман Катил»дә дә, мәхәббәт дастаны буларак билгеле «Таһир белән Зөһрә»дә дә сюжетка ислам белән бергә фал ачып багу, юрау кебек гадәтләрнең килеп керүе шул хакта сөйли. Мондый ярашуның иҗтимагый-тарихи сәбәпләре милли үткәнебезнең күп гасырларны иңләвенә бәйле. Шул ук вакытта бу күренеш гасырлардан гасырларга чарлана килгән халык әсәрләрендә халкыбызның рухи таләпләре чагылыш табу белән дә аңлатыла.

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
**филология фәннәре докторы, доцент,**
**Татарстан Фәннәр академиясе**
**Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият**
**һәм сәнгать институтының баш фәнни**
**хезмәткәре**

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

ПОБЕДА!
1945–2020

# Халык җәүһәрләрен кадерләп

Татарстанның Саба районында халык традицияләрен һәм йолаларын саклау йөзеннән шактый эш башкарыла. «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының Саба районы бүлекчәсе мәдәният йортлары һәм китапханәләр белән берлектә 2019 елда үткәргән «Саба сөлгесе» район конкурсы – шушы нияттән эшләнгән эшләрнең берсе. Бәйге үз бурычын үтәде – яшь буынны татар чигеше белән кызыксындыра алды. Аның төп казанышы да традицияләрне яңартуга омтылыш иде.

Район ирешелгәннәр белән генә тукталып калмады. Быел Саба муниципаль районының Мәдәният бүлеге, Саба һәм Теләче районнарының Хәрби Комиссариатлары, Саба үзәкләштерелгән китапханәләр системасы, Ветераннарның «Боевое Братство» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы һәм «Ак калфак» оешмасының Саба районы бүлекчәсе белән берлектә, шушы теманың дәвамы буларак, яңа бәйге игълан итте. Ул «Җиңү яулыгы» – «Платок Победы» дип атала. Конкурс 2020 елның Хәтер һәм дан елы, Халык иҗаты елы булуын истә тотып оештырыла.

Бәйге темасының кулъяулык булуы очраклы түгел. Хәрби хезмәткә озатылу – ир-егет тормышында зур вакыйга. Бу озатуларның дистәләрчә еллар дәвамында формалашкан традициясе бар. Кызларның сөйгәнен озатканда аңа чигелгән кулъяулык бирүе дә матур бер йолага әверелгән.

Муса Җәлилнең «Кулъяулык» шигырен хәтерлисезме?

*«Аерылганда миңа йөрәк дустым*
*Бүләк итте ефәк яулыгын;*
*Мин ярама яптым ул яулыкны*
*Басар өчен агышын канымның…»*



**Кызыл Мишә авылының чигүче кызлары**



Югары Симет авылы мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Зилә Хассамова һәм Язилә Хәлиуллина (13 яшь)

Татарларда чигелгән кульяулык чисталык, пөхтәлек кенә түгел, мәхәббәт, тугрылык символы да, ә инде озатканда бирелгәне – аерылышу һәм моңсулык билгесе дә. Кулдан чигелгән тукыма кисәге саклаучы булып саналган: күз нурлары салып чигелгән яулыкның үз иясенә янаган хәвеф-хәтәргә киртә булырына ышанасы килгән кешенең.

Бәйгенең беренче бурычы – армиягә озату тантанасында кульяулык бүләк итү традициясен яңарту иде. Булачак солдатка кульяулыкны аның сөйгән кызы гына түгел, классташ кызлары да, хезмәттәшләре дә, танышлары да бирер дип күзалланды.

Бүләк ителгән һәр кульяулык аны бүләк иткән кызның кул эшенә осталыгын күрсәтеп тора. Шунлыктан бәйге, армиягә озату традицияләрен яңарту белән беррәттән, чигү традицияләрен торгызуны, яшьләрне милли бизәкләр иҗат итү алымнарына өйрәтүне дә күз алдында тотты. Саба районында бу уңайдан чигү буенча 18 осталык дәресе уздырылган, аларда 157 кеше катнашкан.

Бәйгедә катнашучылар чигү үрнәкләрен китапханәләрдәге китаплар, гаиләдә саклаган чигүле әйберләр – ашъяулыклар, кашагалар, пәрдәләр һәм башкалар аша өйрәнгәннәр. Кульяулыклар Саба районында гомер-гомергә кулланылып килгән шома җөй техникасы белән чигелгән. Чөнки нәкъ менә шушы техника күп төрле төсләр белән чын мәгънәсендә шедеврлар иҗат итәргә мөмкинлек бирә. Кульяулыкларның һәрберсенә уникаль бизәк төшерелгән, читләре ыргаклы энә белән каймаланган.

Авыл саен оста куллары белән дан алган чигүчеләр бар: Сәлимә Дәүләтова, Халисә Галимҗанова, Саимә Хәерова, Рәмзия Галимҗанова, Гөлсәрия Сөләйманова, Вәсилә Әхмәтова – Явлаштау авылының оста куллы ханымнары. Аларның кул эше үрнәкләре – халкыбызның декоратив-гамәли сәнгате казанышы.

Бүгенге көндә бәйгене оештыру комитеты 163 чигелгән кульяулык кабул иткән. Конкурска кабул ителгән кульяулыклар солдат озату тантаналарында хәрби хезмәткә китүче егетләргә тапшырылачак.

Чигү – борынгыдан килгән мирасыбыз. Халык сәнгатен югалтмыйча киләчәк буыннарыбызга тапшырыйк.

**Евгения ШЕМЕЛОВА,**
**Республика традицион мәдәниятне үстерү методисты**

Тәгъзимә ГАЛИЕВА, Явлаштау авылы китапханәчесе фоторәсемнәре

# Истәлек КУЛЪЯУЛЫГЫ көч биргән...

Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан әдәби үсешнең аерым бер чорына – Бөек Ватан сугышыннан соң язылган әсәрләргә һәм аларның кайбер үзенчәлекләренә игътибар итү сорала. Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләр тәрбияви көчкә ия – дөньяга дөрес караш тәрбияли. Андый әсәрләр вакытлар узып, тормышка карашның кискен үзгәрүе нәтиҗәсендә дә актуальлеген югалтмый, киресенчә, яңа эчтәлек белән баеп, сугыш хакыйкатен яңа буыннарга җиткерүдә үз вазифасын әле дә дәвам иттерә. Бу әсәрләр, сугыш шартларында булсын, тыныч тормышта булсын, безнең илебез кешесе өчен сәяси әхлак кагыйдәләре тотрыклы булып калуын күрсәтә. Ватан алдында торган гражданлык бурычыңны намус белән үтәү, үзеңне дә кызганмау кебек әхлакый җаваплылык кулына корал тоткан кешеләрнең күбесенә хас буларак тасвирланган.

Еш кына фронтовик геройлар күп еллар узгач, сугышта үткәннәрен искә төшерү белән бергә, бу үткәннең хәзерге тормыш өчен әһәмияте турында да уйлана. Фронтовиклар сугышта кичергәннәрен онытылмас кырыс истәлек кенә түгел, кешелек өчен тарихи-әхлакый сабак итеп тә карый. Һәм без моның шулай икәнен әдәби-документаль жанр остасы – Шамил Рәкыйпов әсәрләре мисалында күзәтә алабыз.

Шамил Рәкыйпов очеркларында, кешеләр язмышыннан тыш, образ дәрәҗәсенә күтәрелгән башка объектлар да бар. Шуларның берсе – очеркларда еш кулланылган кулъяулык образы. «Мәңге сакларга» очеркында бу образ аеруча осталык белән гәүдәләндерелә: Гази өчен гимнастерка кесәсендә йөрткән кулъяулыктан да кадерлерәк берни юк. «Сөйгән кызының бүләк кулъяулыгында гүя газиз Туган илнең нәкъ бер өлеше, тутыкмый, күгәрми торган кисәкчәсе. Кулъяулык – ул авылдагы айлы кичләр, кавышулар, таң әтәчләре кычкырган чактагы аерылышулар, аның нечкә билен, иреннәрен тою – гомумән, тормыш, матур киләчәк үзе...». Талисманы була ул аның: дүрт ел буе сугышып, Гази бер тапкыр да яраланмый, «тегенди-мондый гына түгел, тылсымлы яулык ул синең», – диләр аңа дуслары.

Ләкин Газигә бу кулъяулыкны ахыргача сакларга насыйп булмый: ул аны Рейхстаг гөмбәзенә кадалырга тиешле кызыл комачны таякка бәйләп, ныклап беркетү өчен иптәше Мининга бирә. Бу вакытта Гази өчен Германия түбәсенә кадалган флаг кулъяулыкка карагында да кадерлерәк була. Автор бу урында кулъяулыкның сихри көчен тагын да арттыра сыман, чөнки әгәр Газиның куен кесәсендә шул кулъяулык булмаса, Рейхстаг түбәсендә Кызыл Байрак тиз генә балкып җилфердәмәс иде. Татар кешесе өчен бик тирән мәгънәле, күңел җылысы, мәхәббәт символы булган кулъяулык, шул рәвешле, җиңүгә ирешү юлында корал булып әверелә.

Туган илне, яшь чакларны искә төшереп торучы буларак кулъяулык образы Шамил Рәкыйповның «Солдат биштәре» дип аталган очеркына да килеп керә. Кырыйлары алсу каюлы, почмакларында авызына хат капкан сандугачлар чигелгән, затлы хушбуй исе аңкып торган ап-ак батист кулъяулыкны күргәч, очерк герое Садыйкның күрше авылдан килгән кунак кызы – шулай ук кулъяулык бүләк иткән һәм ахырдан тормыш юлдашы булырга ризалык биргән чая Зәйтүнәсе исенә төште.

Кулъяулык образы белән авторның «Кайту» очеркында да очрашабыз. Бу юлы кулъяулык яраланып госпитальгә эләккән Хәсән Заманов дәваланып яткан палатаның тумбочкасы өстендә. Аны Хәсәннең сөйгәне – Гөлҗәннәт чигеп җибәргән. «Аның теләге – совет сугышчысына юаныч бирү, көч, дәрман бирү. Түзегез, явыз дошманны тизрәк җиңеп илгә кайтыгыз, диләр гүя чигүдәге алсу җепләр».

«Сөю дәвам итә» очеркында автор кулъяулыкка берничә җөмлә белән генә кагылып китә. Хушбуй исе аңкып торган чиккән кулъяулык бу очракта да сугышчы егеткә сөйгәне тарафыннан бүләк ителгән. Эпизодик кына булса да, очеркта кулъяулыкның тәэсир көчен ачык тоемларга мөмкин.

Димәк, Шамил Рәкыйпов тудырган кулъяулык образы, сөю, ярату билгесе буларак, сугышчыларга көч, дәрман, тәвәккәллек бирү-

че кадерле әйбер. Туган илне искә төшереп торучы билге-символ буларак файдаланыла. Дөресендә, шул гадәти кульъяулыкның да җиңүгә керткән өлеше бар.

Шамил Рәкыйпов очеркларында еш кулланылган образларның тагын берсе, сугыш тематикасының аерылгысыз элементы, җиңү символы – флаг. Бу образ автор тарафыннан төрле төсмерләрдә, көрәш барышының төрле мизгелләрендә сурәтләнелә. «Мәңге сакларга» очеркында флаг белән без биш урында очрашабыз. Өченче удар армиясе тарафыннан законлы төстә Рейхстаг түбәсенә кадалырга тиешле солдат флагы – сугышчылар өчен бик тә кадерле, изге, кыйммәтле атрибут. «Качып-посып үткәрелгән маевкаларда эшче куеныннан коштай томырылып килеп чыккан, демонстрацияләрдә кургаш ядрәләр белән тишкәләнгән батыр әләмнәрнең дәвамы ул».

Гази кесәсендәге кульъяулык белән бәйләп ясалган, менә-менә Рейхстаг түбәсенә кадалырга тиешле байрак – баш яулыгы кадәр генә сапсыз комач кисәге – «дөньядагы барлык ука-чуклы байраклардан да затлырак» байракка әверелә. «Тау сыртындагы биек таш кыя сыман, тагын да кызарып, мәгърур Байрак җилферди», – дип яза ул Рейхстаг түбәсенә кадалганнан флаг турында.

«Днепр ярларында таллар бар» очеркында авыл советы бинасы өстендәге колгада җилфердәп торган комач сурәтләнә. Бу юлы автор аны хөр, мәһабәт итеп образлаштыра. Чөнки ул бу очракта әлеге җирнең инде безнеке булуын, дошманны илдән кууда тагын бер яңа адым ясалганлыгын күрсәтүче маяк булып әверелә. Шуның белән аның мәгънәсе бик зурая, тирәнәя. Флаг сугышчылар күңелен рухландыра да, нечкәртеп тә җибәрә: «Сагындырган, һай сагындырган ул җаны».

Күргәнебезчә, флаг һәм кульъяулык – Шамил Рәкыйпов очеркларында кыйммәтле, сихри көчкә ия булган образлар.

**Чыганаклар:**
**1. Рәкыйпов Ш.Җ. Аяз күктә карлыгачлар. Документаль-художестволы әсәрләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. – 224 б.**
**2. Рәкыйпов Ш.Җ. Геройлар үлмиләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. – 286 б.**

**Гөлүсә КАЮМОВА,**
**филология фәннәре кандидаты**

**МУСА ҖӘЛИЛ**

# ЯУЛЫК

Аерылганда миңа йөрәк дустым
Бүләк итте ефәк яулыгын;
Мин ярама яптым ул яулыкны
Басар өчен агышын канымның.

Кан табыннан куе кызыл төстә
Яулык минем йөрәк турында,
Сөйли миңа аның җылы назы
Һәм ялкынлы сөюе турында.

Мин чикмәдем, дускай, бер карыш та,
Батырларча алга атладым.
Яулык шаһит: сине һәм илемне
Йөрәк каным белән сакладым.

1942 ел, июль



# Кыр почтасы

## (Музыкаль композиция)

**Татар кызлары чиккән кулъяулыкларны туган җир төсе итеп саклаган егетләрнең күбесе Волхов урманнарында, Сталинград фронтында, Мәскәү асты сугышларында, Курск дугасында, Бөек Новгород сазлыкларында, Европа илләрендә илбасарларга каршы сугышты. Авыл белән фронт арасында өчпочмаклы хатлар йөреп торды. Тылдагы фидакарь хезмәт ул елларда «Барысы да фронт өчен», «Барысы да җиңү өчен» дигән девиз белән башкарылды. Авылда барысы да – хатын-кызлар да, өлкән яшьтәге агайлар да, балалар да фронт өчен эшләде.**

*(Алып баручы сөйләгән арада урындык-эскәмияләр белән хатын-кызлар чыга. Бияләй, перчатка, оекбаш бәйлиләр, сөлге чигәләр.)*

– Әй, кызлар, кайчан бетәр микән бу каһәр төшкән сугыш? Нинди гөрләп торган авылда үле тынлык. Авылның әле бер очына, әле икенче очына кара пичәтле хәбәрләр килеп кенә тора...

– Хаҗиәхмәт абзый аяксыз кайткан... Әхмәдулла – кулсыз...

– Корбангали, Кәшәфетдин дә яраланып кайтканнар...

– Аяксыз-кулсыз булса да, кайтканнар бит әле. Хәсәннекеләрнең биш улына да кара кәгазь килгән әнә! Миңнегали, Миңнәхмәт, Хәмәтзадә, Нурзадә, Хәбибелхак – дөнья бәясе егетләр иде! Идел болыннарында тезелеп басып



печән чабарлар иде! Иииx... Ана йөрәге ничек чыдарга кирәк...

– Адайдан Мансура, Сәрдектән Мәгъфүрә, Чишмәбаштан Закирәләр дә китеп бардылар әнә. Исән-сау гына кайтсыннар инде. Әйдәгез, ахирәтләр, персидәтел Хәким абзыйга бергәләп хат язабыз. Факия, син грамотный, хәреф танышсың, әйдә әйтеп торабыз, син яз!

*(Факия хат яза.)*

– Барчабыздан сәлам әйт. Басу-кырлардагы, фермалардагы авыр хезмәт хатын-кыз, карт-коры, бала-чага җилкәсенә өелде. Ач маллардан торган фермалар Мәймүнә апага калды, диген.

– Авылның биш бригадасын – Кәнҗибану, Маһинур, Дилбәр, Нәҗияләр җитәкли, дип әйт.

– Хат ташучы Мәугыйзә әллә никадәрле йортка: «Батырларча һәлак булды», – дигән кайгы кәгазьләре алып килде. Яз, ахирәт, барын да әйтеп яз!

*(«Син кайтмадың». С.Урайский сүзләре, М.Мозаффаров көе, җыр башкарыла.)*

– Күпереп пешкән икмәк тәме онытылды. Халык алабута валмасы, черек бәрәңгегә күчте. Ачтан үлүчеләр булды. Сабыйларын җир куенына салган аналарның да күз яшьләре төшәр әле бу дошман башына, дип яз.

*(«Әнкәй». З. Нури, нәфис сүз.)*

– Авылдан фронтка, авыл халкы тырышып асраган сарык йоннарыннан хатын-кызларның кул җылысын кушып бәйләгән күпме бияләй-оекбаш, автоматчылар өчен махсус ике бармакчасы аерып бәйләнгән пирчәткәләр салынган фанер посылка тартмалары җибәрелде.

*(Посылка тартмалары күтәреп, чүкечләр тотып олы агайлар керә.)*

– Әйдәгез, авылдашлар, солдатларга посылкаларны бүгеннән әзерләп куйыйк.

– Әйдәгез, әйдә!

– Укытучы Мостафин Рәшит энекәштән хат килде. Офицер булдым, дигән. Авыл хәлләрен сорашкан. Аңа да хат яздык, бергә салырбыз.

*(Хат күрсәтелә.)*

– Авыл хәлләрен барын да яздыңмы? Мәгъсүмәнең 12 яшьлек улы Камилнең сугышка чыгып киткәнен дә яздыңмы?

– Яздым. Аны кире борып кайтарганнар иде инде бер, тагын киткән!

*(Тартмалар сәкегә тезеп куела. Берәм-берәм аларга әйберләр салына.)*

– Нәбиуллам хакына дип җибәрәм. Нәбиулла Ленинград блокадасына эләккән бит. Ачтан бик интегәбез, бака тапсак, сөенеп ашыйбыз, дигән.

– Үзебезнең авылдан Абдулла, Солтан, Адайдан Гыйлмөхәммәт, Буҗидан Газиз дә шунда икән! Бик яман начар җир, ди.

– Абыйларым Гыйлмөхәммәт, Габделхак исән-сау кайтсыннар.

– Балаларым «Әти» дип әйтә алсыннар иде!

– Туйганчы ипи ашарлык тыныч көннәр җитсен иде!

– Сабан сөрергә ач үгезләр түгел, таза атлар булсын иде!

*(Ирләр: «Амин, шулай булсын», – дип хуплап торалар, бер ишеләре посылка кадаклый.)*

*(Баламишкин көенә «Гитлер такмаклары» башкарыла.)*

*Кулымдагы йөзегемнең исеме Нурания,*
*Өзелеп сөйгән ярларымнан аерды*
*Германия.*
*Сукыр Гитлер сабан сөрә,*
*чак-чак атлый атлары,*
*Алдын-артын белми кача корчаңгы*
*солдатлары.*
*Гитлер багана башында*
*чабатасын киптерә,*
*Безнекеләр арттан килеп*
*пулеметтан сиптерә.*
*Өсләрендә соры шинель,*
*билләрендә перәшкә,*
*Безнекеләр җиңеп чыгар*
*Гитлер белән көрәштә!*

– Әйдәгез, авылдашлар, бу посылкаларны фронтка җибәрик! Әйдәгез!

*(Посылкаларны ала чыгалар. Сәхнә ярымкараңгы, сугыш канонадасы ишетелә. Солдатлар чыга, привал күренеше. Эчтән тавыш: «Привал».)*



– Егетләр, әйдәгез, ял итеп алабыз! Авылга хат та язасы бар.

– Харис, без хат язган арада, рус егетләре яраткан теге матур җырыңны җырла әле. Әйдә, дус, тарт гармунның колагын!

– Әйдә егетләр, безнең танкистлар турындагы җырны җырлыйбыз!

*(Сугыш турында җырлар башкарыла.)*

– Рәшиткә хат бар бүген. Туган яклардан!

*(Почтальон кыз егеткә хат бирә. Кычкырып бергәләп хат укыйлар.)*

«Сәлам сез ки ерак җирләрдә сугыш кырында йөрүче кадерле авылдашыбыз Рәшит энекәш! Сиңа сагынычлы күп сәламнәр җибәреп калабыз. Авылда хәлләр мактанырлык түгел. Кайта алмаучылар исемлеге көн саен арта. Маллар да ачтан кырыла. Атлар күтәрәмгә калды. Яраланып кайтучылар да бар. Хәким абыйдан соң, сельсовет итеп фронттан кайткан Мәлик абыйны куйдык. Олысы-кечесе барыбыз да Җиңү өчен дип тырышабыз. Авылдашыбыз, умартачы Латыйпов Рәшит барлык җыйган акчасын дәүләткә самолет төзергә дип тапшырды. Шушы көннәрдә аңа иптәш Сталиннан Рәхмәт хаты килеп төште. Кыр эшләрендә күрше колхозлар белән ярышып эшләүне дәвам итәбез. Укытучылар бар да ашлык чистартырга йөри. Агитбригада белән концертлар куялар. Концертлардан җыелган 5 мең сум акчаны танк колоннасына җибәрделәр. Комсомолкаларыбыз да сынатмый, ир-егетләр булмаса да, Нократ арьягына печәнгә чыктык. Гарифулла абзый чалгыларны кайрап торды. Гайшәбикә колхозда завхоз хәзер, бик ыстругий. Сезнең тизрәк җиңеп кайтуыгызны телибез. Исәнлек белән күрешү көннәрен көтеп калабыз. Кабат сәлам белән, хат көтеп туганнарың, авылдашларың дип белерсең».

– Тарт әле тагын, Шәүкәт дус, баяныңны, кызлар биерлек итеп уйнат әле бер!

*(Берәү баянда уйнап җибәрә, икенчесе бии.)*

– Әйдәгез, иптәшләр, Татарстаннан концерт бригадасы килгән, якташларны тыңларга барыйк!

*(«Матур булсын» – күмәк җыр.)*

**Рәмзия ХӨСӘЕНОВА,**
**Кукмара, Зур Сәрдек авылы**

**Рәсемнәрдә:**
**Кукмара районының Зур Сәрдек мәдәният йорты «Сердәш» фольклор ансамбле әгъзалары**

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

# Челтәр элдем читәнгә, җилфер-җилфер итәргә...

**2019 елның ноябрендә оештырылган экспедициябезнең максаты – Яңа Чишмә районы авылларында булып, җирле халыкның гамәли сәнгате һәм һөнәрчелеген өйрәнү иде. Әлеге мәкалә нигезендә авыл мәктәбе музейларында һәм йортларда сакланган кул эшләрен анализлау һәм кул эше осталарының үзләре белән аралашу ята.**



Кашага. Нургатина Дания Нәҗип кызы (1950 елгы) кул эше, Чаллы Башы авылы



Кашага фрагменты. Акъяр авылы музееннан, Әхмәтова Асия Хатыйп кызының (1938 елгы) кул эше



Япма. Зирекле авылының Халык иҗаты һәм көнкүреше музееннан, Газыймова Зәйтүнә Гафур кызының (1949 елгы) кул эше

Кулдан бәйләнгән челтәрләр гомер-гомергә йорт бизәге булган, гади генә киемне дә затлы, нәзакәтле итеп күрсәткән. Бүген безнең игътибар үзәгендә – челтәр. Әйе, йорт интерьеры һәм кием бизәге булган нәфис челтәрләргә бергәләп сокланырбыз.

Яңа Чишмә районы XX гасырның утызынчы елларында оешкан. Муниципаль районның составы бик төрле – биредә татарлар да, руслар да, чуашлар да, башка халык вәкилләре дә яши. Районда һөнәрчелек һәм декоратив-гамәли иҗат зур үсеш алган – биредә һәр ир-ат төзүче дә, балта остасы да, һәр хатын-кыз тегүче, чигүче, тукучы, бәйләүче, кыскасы, кул эше остасы. Шуңа да биредә йорт эчләре чигүле-челтәрле эшләре белән сокландыра.

Бу яклардагы авылларда кулдан бәйләнгән челтәрләр киң таралган. Слобода Архангельская дип аталган рус авылында һәм Әдәмсә татар авылының мәктәп музеенда ришелье техникасы белән чигелгән челтәрләр очраттык. Берничә төрле техника кулланып бәйләнгән челтәрләр дә бар. Нигездә челтәр ак, сирәк кенә кара, кәтүк җебеннән үрелгән була. Аеруча нәзекләре – мулине җебеннән. Йон җебеннән үрелгәннәре дә очрады.

Яңа Чишмә районы челтәрләре бик нәфис эшләнгән, рельефлы яки гипюр эшләр юк дәрәҗәсендә. Нәфис тукыма геометрик


1


2


3





**1. Шәл фрагменты. Зирекле авылының халык иҗаты һәм көнкүреше музееннан**

**2. Сөлге фрагменты. Акъяр авылы музееннан**

**3. Мендәр тышы. Шахмай авылы, Усманова Лилия Әсхәт кызының (1969 елгы) кул эше**

**4. Салфетка. Шахмай авылы, Усманова Лилия Әсхәт кызының (1969 елгы) кул эше**

**5. Челтәр яка. Акъяр авылы музееннан, Шәйхетдинова Саҗәрә Миңневәли кызының (1923-2004) кул эше**

**6. Салфетка. Акъяр авылы музееннан, Мифтахова Маһирә Фәтхетдин кызының (1924-2018) кул эше**

фигуралар белән челтәрләнгән, читләре тешле яки тигез рәт булып бахрома яисә җепләрдән чуклар ясалган.

Челтәрләрдә ромблар, квадратлар, түгәрәкләр һәм овallардан торган геометрик бизәкләр, диагональ һәм вертикаль сызыклар еш кулланыла. Чәчәк, яфрак һәм бөдрәләрне хәтерләткән үсентеле бизәкләрне дә еш очратырга була. Зооморф мотивлары да бар, болар гадәттә пар күгәрченнәр ясалган кашага, декоратив сөлге читләре.

Челтәрләрнең кулланылышына килсәк, аларны гадәттә урын-җир комплектында очратабыз. Мәсәлән, «кашага» белән караватның аскы ягы томаланган. Аның буе караватозынлыгына туры китереп 2 метрлы булган, киңлеге төрлечә. «Караватбашы» – челтәрле пар япма – караватның баш-башларына элентән. Болар караватастына куелган әйберләрне каплап торган, чөнки шкафлар урынына әйберләр сандыкларда һәм чемоданнарда саклanган, алар урын алып тормасын өчен караватастына урнаштырылган. Челтәрләр

мендәр тышларын да бизәгән. Тулысынча кулдан бәйләнгән челтәр япма да очраттык (Чертуш авылы, Мусина Рауза Ярулла кызының (1936-2018) кул эше. 50 нче еллар).

Өстәл бизәүдә кулланыла торган челтәрләр икенче төркемне тәшкил итә. Болар – төрле зурлыктагы бизәкле тастымаллар; поднос өстенә ябa торган «төре өсте» тоташтырып тора, икона астына «төре алъяпкычы» эленгән. Болар барысы да чигешле һәм челтәр бизәкле булган.

Чит-читләре челтәрләр бәйләнгән сөлгеләр дә игътибарны җәлеп итә, сөлге чите гади генә чукландырып куелган очракта да ачык чигешләре белән балкып тора. Димәк, чигә белгән кеше челтәрен дә бәйли белгән дигән нәтиҗә чыга.

Йорт бизәлешендәге тагын бер челтәрле элемент – «тәрәзә челтәре» һәм «түрләмә», ягъни ишек каршындагы стенага – түшәм астына эленгән тукыма.

Киемнәрдә челтәр «эчке күлмәк» итәгенбизәү өчен кулланылган. Ул матурлык өчен генә түгел, практик ягын да уйлап ясалган:



4.



6.



5.

нәфис каплавычлар, самавыр япмалары. Ашъяулыклар берничә төрле бизәлгән: тукыма периметры буйлап челтәр тасма тегелгән, үзәгенә челтәр бизәк куелган. Шулай ук, челтәр ашъяулыклар да очрады – монысы инде аеруча зур осталык һәм пөхтәлек таләп иткән хезмәт.

Керәшеннәр яшәгән Ленино авылында безгә икона торган почмакны бизәүче «төре алды» дип аталган япмаларны да күрергә туры килде. Комплектка «төре бистәре», «төре өсте» һәм «төре алъяпкычы» керә. «Төре бистәре» – иконаның янякларына эленгән пар сөлгеләр, аларны өске яктан

челтәр итәккә күтәрелергә бирмичә, аны аска тартып торган.

XX гасырда челтәр якалар да булган.

Челтәр шәлләрне әлегәчә бәйлиләр (Чаллы Башы авылы, Дәүләтшина Айгөл Айрат кызы (1984 елгы) һәм Акъяр авылы, Фәрхаева Гөлүсә Фатыйх кызы (1989 елгы) кул эшләре).

Тикшеренүләребезгә йомгак ясап, шуны әйтә алабыз: ун авылда респондентлар белән аралашып һәм музей тупланмаларын өйрәнеп 41 кул эше остасы ачыкланды, аларның кул эшләреннән 700 фоторәсем ясалды. Яңа Чишмә челтәрләре нәфислеге, сәнгати гүзәллеге белән сөендерде.

**Алсу БОРҺАНОВА,**
**Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре**

Автор фоторәсемнәре

# Урта гасыр классик татар сәнгатендә ТАНБУР МУЗЫКА КОРАЛЫ

Урта гасыр татар мәдәниятенең язма чыганакларында искә алынган музыка кораллары арасында танбур иң еш кулланылучысы. Бу аның мөселман шәрыкъ илләрендә иң борынгы һәм иң киң таралган музыка коралы булуына бәйле. Танбур мөселман сәнгате үзәге булган шәһәрләрдә – хан сарайларында хезмәт иткән профессиональ иҗатчылар арасында популярлык казанган.



Бүгенге көндә хәрәсән танбурында башкару традицияләре уйгур, үзбәк, таҗик кебек халыкларның сәнгатендә саклана һәм үсешен дәвам итә.

## Танбурның төзелеше

Танбурның төзелеше, үлчәмнәре түбәндәгечә: агачтан груша шәкелендә уеп эшләнелгән корпуслы, калын сеңер пәрдәләр бәйләнгән яисә җилем белән ябыштырылган агач пәрдәле озын саплы, 3 тимер яки җиз кыллы уен коралы. 1 нче һәм 3 нче кыллар унисонга көйләнә, 2 нче кыл аларга квартага яисә квинтага. Кыл тавышы имән бармак тырнагы белән яисә плектр (чирткеч, нәхен) белән чиртеп чыгарыла. Танбурның гомуми озынлыгы 1100-1300 мм.

## Танбур элитар сарай музыкасында

Идел буе татарларының музыкаль мәдәниятендә танбурны куллану турындагы иң беренче ышанычлы мәгълүматлар Казан ханы Мөхәммәт Әмин сараендагы мәшһүр җырчы Дәрвиш Шадый һабәши исеме һәм иҗаты белән бәйле.

Татар тарихы һәм әдәбияты белгечләре тарафыннан язылган хезмәтләрдә бу факт урта гасыр әдәбияты ядкәре саналган, Мирза Заһиретдин Мөхәммәт Бабур тарафыннан иҗат ителгән «Бабурнамә»[1] әсәреннән алынып тасвирлана.

Соңгы вакытта фәнни әйләнешкә Идел-Кама төбәгенең урта гасыр тарихын чагылдырган яңа чыганаклар керде. Мәсәлән, Урта Азиянең күренекле музыка галиме, шагыйрь, тарихчы Дәрвиш Гали Чәңги иҗат иткән «Төхфәт-с Сорур», «Рисалә-и мусика»[2] әсәрләрен тасвирлаган хезмәтләр. Алар арасында үзбәк галиме Г. Фитрәт хезмәтен аерым күрсәтеп була[3]. Бу чыганаклардан күренә ки, Дәрвиш Шадый һабәшинең тәрҗемәи хәле Һират шәһәрендә, Солтан Хөсәен Байкара сараенда җырчы буларак башланып китә. Сарайда аның иҗатын югары бәяләгән кешеләр арасында вәзир хезмәтен үтәгән, бөек шагыйрь Галишир Нәваи дә була. Чама белән 1502-1503 еллар тирәсендә Дәрвиш Шадыйның язмышы аны Казан ханы хезмәтенә китерә. Ул дәвердә Казанда да, Алтын Урда варислары булган Әстерхан, Кырым, Себер ханлыкларының мәдәни мәркәзләрендәге кебек үк, классик шигърият, элитар сарай музыкасы да үсеш алган була. Әлбәттә, бу төбәкләрдә үсеш алган традицияләр, иҗатчылар үзара тыгыз бәйләнештә булган[4]. Риваять буенча, Дәрвиш Шадыйның Мөхәммәт Әмин хозурындагы беренче чыгышы гыйбрәтле була. Ул Һират белән Бохарадагы иң популяр әсәрләрне башкара һәм ханның күңелен күрә. Нәтиҗәдә уенчылар кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә, хөрмәтләнә.

## Танбур суфичылык сәнгатендә

Танбур Идел буе татарларында урта гасырларның соңгы дәверендә (XVIII-XIX йөз башында) суфи-дәрвишләрнең музыкаль гамәлиятендә кулланылган. Билгеле булганча, Сембер губернасы Зөябашы авылында

[1] Захир-ад-дин Мухаммад Бабур. Бабурнаме. – Ташкент: Главная редакция энциклопедий. – С. 182 б, 190 а.
[2] Рашидова Д. Ученый-музыкант, поэт и историк Дарвиш Али чанги // Культура Среднего Востока – развитие, связи и взаимодействия. – Ташкент, 1992. – С. 51-69.
[3] Фитрат Габдрауф. Узбек классик музикаси ва унинг тарихи. – Тошкент, 1993. – Б. 44. (үзбәк телендә).
[4] Макаров Г.М. Династии Хабаши и Габяши в Заказанье // Заказанье: Проблемы истории и культуры. Материалы конференции. – Казань: Заман, 1995. – С. 78-81.



Геннадий Макаров танбурда уйный

яшәгән Җәгъфәр ишан әс-Сафари күренекле суфи булу белән генә түгел, оста итеп танбурда уйнавы белән дә дан казана.

Җәгъфәр ишан Идел буендагы ислам дине һәм сәнгате үсеше тарихында билгеле шәхесләр исемлегенә керә. Аның турында Таҗетдин Ялчыгол, Шиһабетдин Мәрҗани[5], Ризаэтдин Фәхретдин һәм башка галимнәр язган.

Татар музыкасы тарихында ул суфичылык катламын һәм өслүбен тәшкил иткән юнәлеш вәкиле буларак мәгълүм. Җәгъфәр ишан үтә зур осталык белән хөрәсән танбурында (төрки танбурда) уйнаган һәм үзенең сәнгатенә мөритләрен дә өйрәткән. Риваятьләрдән күренгәнчә, ул төрле уен коралларында уйнап, касыйдә, газәлләр көйләп суфи зикерләрен оештырган. Җәгъфәр ишан һәм аның мөритләре еш кына төрле дини бәйрәмнәргә, мәҗлесләргә чакырылган. Алар анда нечкә зәвык белән суфичылык белән сугарылган музыкаль-шигъри әсәрләр башкарган.

Җәгъфәр ишанның тулы исеме – Җәгъфәр бине Габид бине Исхак бине Котлыгмөхәммәт бине Нариман әс-Сафари. Ул Уфа губернасының Чишмә волостенә караган Сафар авылында туган (хәзерге Башкортстан, Чишмә районы, Сафар авылы)[6]. Бик яшьли ятим кала. Аның анасы Сафар авылы мулласы Хәлил бине Асылхуҗа бине Әмирхан бине Шәриф кызы Рәҗәб исемле хатын була. Ире вафат булгач, ул Арслан авылы мулласына кияүгә чыга. Җәгъфәрнең балачагы Арслан авылында үтә (әлеге авыл кешеләре этник чыгышлары буенча мишәр татарлары кавеменнән була). Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, Бохарада укый, белемен камилләштерү өчен Кабулга китә. Монда ул күренекле дин белгече, галим буларак шөһрәт казанган ишан Фәезхан Хазырхан әл-Кабулинең мөрите була. Дин белеменең югары баскычларына күтәрелгәч, югары рухи камилият дәрәҗәләрен үзләштерә алгач, Җәгъфәр ас-Сафари үзенең рухи остазыннан язма рәвештә иршаднамә һәм мөстәкыйль рәвештә үзе ишан булып мөселманнарга белем нуры һәм рухи тәрбия бирү өчен фатиха ала.

Җәгъфәр ишан үзенең музыкаль-теоретик белемен, төрле уен коралларында уйнау осталыгын Бохарада һәм Кабулда яшәгәндә ныгыта. Чөнки анда суфиларның төрле дини-гыйбадәт мәҗлесләрендә музыка һәм шигърият сәнгатен куллану гамәлияте киң таралган күренеш була. Табигый ки, болар барысы да аңа классик ислам сәнгатенең эстетикасын һәм теориясен яхшырак үзләштерергә мөмкинлек бирә.

Ул еш кына бу тирә-яктагы дәрвиш ханәкәләренә бара һәм андагы суфилар белән очраша. Күп тапкыр Болгар, Биләр тирәләрендәге мөселман әүлияләренең дөрбәләренә зиярәт кыла. Ул, шулай ук, хәзерге Балтач районы Оры авылында яшәгән Хәбибулла ишан белән элемтәдә тора, Ирнә суы буена урнашкан Мәлем авылына һәм башка урыннарга да бара. Җәгъфәр ишанда кешеләрне төрле авырулардан имнәү сәләте дә көчле була.

Җәгъфәр ас-Сафари суфичылык хәрәкәтендә актив катнаша һәм ишан булып үзенә мөритләр туплый, ханәкә сала. Аның рухи мәзһәбе Нәкышбәндия тәгълиматенә нигезләнә. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, Җәгъфәр ишан, суфичылык тәгълиматына өндәп, ерак сәфәрләргә чыга. Җәгъфәр ишан олыга-

[5] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар / Китапны тәрҗемә итүче һәм төзүче Ә.Н. Хәйруллин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1989. – Б. 278.

[6] Макаров Г.М. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан Башкортстанның Чишмә районына оештырылган фольклор-этнографик экспедиция материаллары (1-10 июль, 1994 ел).

еп, 1831 елда вафат була һәм Зәябаш авылы зиратына җирләнә.

## Танбур борынгы татар шигъриятендә

Музыка кораллары, аерым алганда, танбур турында үтә кыйммәтле мәгълүматлар Габдерәхим Утыз-Имәни әсәрләрендә бар. Аның «Гуариф-ез-заман» исемле поэмасында Зәй, Шушма, Чирмешән елгалары тирәлегендә урнашкан мөселман авылларында хәтта бербөтен ансамбльләр булганлыгы языла:

*Кубыз, танбур вә нәй, гайре уенлар*
*Килер уртага кыз вә җәванлар.*
*Бу рәсвалык белән та сөбхе садикъ,*
*Идәрләр эш шәятинга муафикъ*[7].

Монда, гадәти авыз кубызыннан ислами шәрыккә нисбәтле классик уен коралларыннан: танбур һәм нәй телгә алына. Бу мәгълүмат әлеге уен коралларының тагын да борынгырак дәверләрдә үсеш алган сәнгать белән эзлеклелеген күрсәтә.

Габделҗаббар Кандалый иҗатында да классик ислами сәнгатькә бәйле сыйфатлар күрергә, төрле музыка коралларын куллану турында мәгълүмат очратырга мөмкин:

*Уен-көлке мәкянендә вара күрмә дәр-ан инә,*
*Дотып зиннәт, идеп нәкъши вара*
*бер мәҗлеси вәхши*
*Бу савтә әйләмә рәгъбәт авазе*
*фигъл иде ләгънәт;*
*Кеше дәф орса һәм танбур,*
*кидәсән сөхбәтендин дур*[8].

Югарыда телгә алынган авторларның әсәрләреннән күренгәнчә, мөселман өммәте мохитендә яшәгән һәм аңа тугры калган татар яшьләре кубыз, танбур, нәй, дәф кебек уен коралларында уйнап күңел ачкан, өстәвенә аларны татар халкы үзенең иң авыр сынау көннәрендә, ягъни XVI йөз уртасыннан XIX йөз уртасына кадәр саклап кала алган.

Югыйсә, урта гасырларның соңгы дәверендә татар халкы яшәгән авыллардагы рухи аталар, абызлар үзләренең тәртип, иман һәм йола тамырларын саклау эшендә үтә кырыс булганнар, дөньяви сәнгатькә катгый рәвештә каршы торганнар. Алар башка сыймас могҗиза рәвешендә сакланып калган иске төрки-татар уен коралларын «гөнаһ» һәм «бидгать» дип игълан иткәннәр.

Күренекле дин галиме, тарихчы, мәгърифәтче Таҗетдин Ялчыголның иҗади мирасы шул чордагы татар тормышына нисбәтле күп мәгълүматны үз эченә ала. Инструменталь музыка сәнгатенә караган материаллар аның безгә билгеле булган ике хезмәтендә чагыла. Ул хезмәтләрендә Шәһри Болгар каласы хәрәбәләре буенда балчыктан ханәкәләр төзеп яшәгән суфи-дәрвишләрне тасвирлый һәм аларның төрле музыка коралларын, шул исәптән: танбур һәм гөслә кулланганнары турында яза. Бу мәгълүматлар татарларның XVIII йөз азагындагы инструменталь сәнгате турындагы билгеле фактик материалларны тагын да киңәйтәләр һәм тулыландыралар.

## Танбур XXI гасырда

Казанда танбурда уйнау традицияләрен тергезү туксанынчы елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында башланып китте. Татар җәмәгатьчелеге танбур яңгырашын Татарстан радиосы һәм телевидениесе аша шул елларда ишетте. Казан дәүләт консерваториясе студентлары дәресләрдә танбурда уйнау алымнары белән таныша башлады. Бүгенге көндә танбурда уйнау сәнгате буенча тәҗрибәләр үткәрелә.

Танбурны заманча сәнгатьтә яңадан тергезү өчен аның урта гасырлар татар мәдәниятендәге урынын, куллану һәм таралыш дәрәҗәсен ачыклау таләп ителә. Бу музыка уен коралы белән бәйле күп кенә яңа ачышлар булып, яңа чыганаклар табылыр әле. Алар, әлбәттә, татар халкының танбур сәнгате тарихын тагын да тулыландырыр һәм баетыр. Бу гамәлләр, үз нәүбәтендә, урта гасыр татар музыка классикасы сыйфатларын, аның шигъри-вокаль, инструменталь өлешләрен татар халкының хәзерге мәдәниятендә куллану мөмкинлеген дә киңәйтер.

**Геннадий МАКАРОВ,**
**фольклор белгече, сәнгать фәннәре кандидаты, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе доценты**

Рөстәм МӨХӘММӘТҖАНОВ фоторәсеме

[7] Утыз-Имәни Габдерәхим. Шигырьләр, поэмалар / Төз. Ә.Шәрипов. – Казан: Тат.кит.нәшр.,1985. – Б. 32-35.

[8] Кандалый Габделҗаббар. Шигырьләр һәм поэмалар / Төз. М. Госманов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1988. – Б. 268-269.

# ШАГЫЙРЬ ҺӘМ МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР



**Сабан туе.
Әлфия НУРХАМӘТОВА
рәсеме,
Аксубай төбәкне
өйрәнү музее
директоры**

Күренекле татар һәм башкорт халыклары шагыйре Шәехзадә Бабичның «Сабантуй һәм милли бәйрәмнәр» шигыре 1912 елда иҗат ителгән. Бу вакытта булачак шагыйрьгә 17 яшь һәм ул Уфадагы мәшһүр «Галия» мәдрәсәсендә белем ала. Әсәр мәдрәсәдә имтиханнарны тәмамлап, Уфа губернасының Бөре өязенә кергән Әсән авылына (туган нигезенә) ялга кайткан чорында язылган. Бу чор апрельнең икенче яртысыннан алып июль башларына кадәр вакытны үз эченә ала. Нәкъ менә шушы вакыт аралыгында булган бәйрәм-йолаларны тасвирларга алына шагыйрь. Шушы вакыт аралыгында Әсән төбәгендә өч төп йола бәйрәме уздырыла: апрель яисә май аенда – «Карга боткасы»; июньдә – «Сабан туе»; июнь ахырында – июль башында – дүрт көн буе бара торган төбәк (берничә авылны берләштергән) җыеннары.

Сүз уңаеннан, Әсән төбәгендә бу йола бәйрәмнәре хәзер дә шул ук вакытларда һәм шундый ук тәртиптә уздырыла; аның форматы һәм эчтәтлеге генә бүгенге заман таләпләренә һәм шартларына яраклы рәвештә үзгәртелгән. Әйтик, хәзер Әсән төбәгендә уздырыла торган җыен «Күәш җыены» дип атала һәм ул бу елга буенда урнашкан барлык авылларны да берләштерә. Аның төп максаты – елга буенда утырган татар авылларын һәм мәдәни, һәм икътисадый, һәм тарихи яктан тәкъдир итү, аларның шәҗәрәләрен барлап, авылның горурлыгы булырдай күренекле шәхесләрен күрсәтү. Гадәттә, бу оештыру эшләрен элеккеге авыл советлары ролен башкаручы авыл муниципаль берлеге хакимияте һәм шушы җирлектәге аграр хуҗалык җитәкчеләре башкара. Элеккеге чорлардагы кебек, бүген дә милли йолаларның әйдәүче көче булып, дин әһелләре, имамнар тора. Шулай ук мәктәпләр һәм иҗтимагый оешмалар актив катнаша.

Ш. Бабич шигырендәге милли йолалар татар халкының рухи традицияләре нигезендә тасвирлана. Йөз ел элек чын татар авылында үткәрелгән татар мәдәни йолалары мәшһүр шагыйрь күзаллавында укучы өчен кызык тоелыр дип уйлыйм.

# САБАНТУЙ
# ҺӘМ МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР

Язга каршы көн батырлангач, кышыңның мартлары,
Банкрот байдан, бетергәч күп карын, март «шартлады».

Кар йокарды, инде күр син безнең апрель башларын:
«Аһ, харап булдык», – дип кыш түкте күздән яшьләрен.

Сипте апрель күз яшенең өстенә яңгырларын,
Сулады кырны, аяк астын, халык ындырларын.

Акты сулар, кайда уй бар – шунда сулар тулдылар,
Артылып аккан сулар зур елгага кушылдылар.

Китте кызлар, төрле сүзләр сөйләшеп, «гөл-гөл» диеп,
Җырлашып, «ак гөлгә кунып сайрады былбыл», диеп.

Чыкты маллар һәммәсе ташлап караңгы абзарын,
Күп тели торгач, алар да күрде инде язларын.

Кыт-кыт кыткылдый тавыклар, казлары каңгылдаша,
Кичкә табан әллә кайда бакалар бакылдаша.

Ямь-яшел кырлар яшәрде, ярды яфрак бар агач,
Килде көньяк кошлары: аккош, сыерчык, карлугач.



**Анастасия БЕЛОБОРОДОВА (15 яшь) рәсеме, Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы**

Имтихан тотты шәкертләр, җитте апрель уртасы.
Әйтә һәркем: «Башлана Сабантуй, апрель иртәсе...»

Күп малай, иртә торып, кычкырды: «Карга, карга...» – дип,
Өй саен йөренә малайлар: «Бир, апай, ит-ярма?» – дип.

Бер бүлек малай, егетләр, бер бүлек – кыз, корткасы,
Тау башына менделәр пешерергә «карга боткасы».

Дәртләнеп, җырлап егетләр тарттылар гармуннарын,
Кайсысы кызлар белән уйнап таратты моңнарын.

Төшлек үткәч, ботка беткәч, кыз-егетләр кайттылар,
Иртәгә күкәй җыябыз, дип, йокларга яттылар.

Иртән иртүк йөрде малайлар берәр токсай элеп,
Өйдән-өйгә йөгереп, бу көнне тансык белеп.

Көн күтәрелгәч, балалар өйләренә кайттылар,
Инде чыкты атлылар һәм анда-монда чаптылар.

Җенләнеп, гаскәр кебек акрып йөри бу атлылар,
Чыкма урамга җәяү, чыксаң әгәр, таптарлар.

Соңыннан, тәгәрмәчләнеп бер җирдә торгач, атлылар
Барсына кәнфит, кераәндил һәм күкәй тараттылар.

Бу да үтте, инде иртән ат чабыш мәйдан була,
Анда сөлгедән, керәндилдән, түбәтәйдән була.



**Майя ШӘМСЕТДИНОВА (12 яшь) рәсеме, Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы**

Үткәч апрель, ямьле, матур май килер, майдай эреп,
Май аенда моңлы кошлар моңланып сайрар эреп.

Басуга китәр халык, сука, сабан дыңгырдатып,
Җир сөрерләр анда атлар тирләтеп, дөпелдәтеп.

Май халыкны басуга куар һәм сыердай безләтер,
Көннәрен бушка җибәртми, көн дә, көн дә эшләтер.

Майны үткәргәч халыклар, эш белән июнь җитәр,
Милли бәйрәмнәр килерләр, бик хозур җыен җитәр.

Пар атын чуклап, тагын куш кыңгырау пыр туздырып,
Әй килер кунак җыенга, килер күзләр кыздырып.

Бер көтү малай барып ачар басуның капкасын,
Ыргытыр кунак аларга, күчтәнәч, дип, акчасын.

Кырга чыгарлар халыклар һәм кунаклар барчасы,
Һәм килер Г... авылының вак-төяк тауарчысы.

Бер урынга сәүдәгәрләр торпыша корып торыр,
Арлы-бирле болганып, шунда халык йөреп торыр.

Кыңгырау һәм дә тарантас таушына дөнья тулар,
Бер ягыннан җенләнеп, исрек агайлар шәп узар.

Күп төялгәннән аларның арбасы сыгылып төшәр,
Кайсы салыныр арбадан һәм кайсысы егылып төшәр.

Күп булыр бутылка болгап, җирне ертып җырлаган,
Ул бутылкалар сугылган, чылтыраган, кыйраган.

Анда, мәйданда көрәшә һәр талапкар, көчлеләр,
Хәйләкәрләр, йөрәклеләр һәм юан, киң түшлеләр.

Җыйды мәйдан башлыгы яулык вә акча, тастымал,
Барсы булды илле яулык, байтак акча, башка мал.

Чыкты да яланга бер озын таякны какты ул,
Башына җыйганнарын җилбердәтеп такты ул.

Агылып-агылып килде мәйданга читтән күп адәм,
Кыз-хатын бер җиргә җыелган, яшел, күк ситсадан.

Һәр авылның да була киң ат чабыш мәйданнары,
Яшәсен безнең халыкның милли бу бәйрәмнәре!

Иллә шәп булды көрәшләр, килде атлар дүрт эрәт,
Бик тә әйбәт үтте мәйдан, булмады тик рәтлерәк.

Әллә ничә ат җигелер, атка яулык бәйләнер
Дә егетләр, дәртлеләр, бик шәп җыенны әйләнер.

Елмаер, муйнын борыр һәм яңгыратып сызгырыр,
Боргылатып сызгычын, сызып күңелне өздерер.



**Регина БӘДРЕТДИНОВА (15 яшь) рәсеме, Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы**

Бер тарантаска утырып скрипкачы егет,
Ду килер атлар, җыенны әйләнер пыр туздырып.

 Япь-яшел күрекле гармунын ялтыратып тарткалар,
Һәр кешегә дәртле йөз белән көлеп бик шат карар.

Төш авышкач, сахрадан кайтыр халык, җыен бетәр,
Төйнәлеп яткан халык күңлендәге төен бетәр.

Чүмәлә чәллә мөәзиннәр, габделкарилар, муллалар
Өй саен ашка йөрер, бер тин вә барнау алгалар.

Көн дә ун өйдә сыйланып муллалар дүрт көнгәчә,
Мулланы йөретер халык баштарак көрсенмичә.

Дүрт булып, бишенче көн үтәр, кунак кайтып китәр.
Шундый ук як-якта җыеннар булып, июнь үтәр.

*1912 ел*

**Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,**
**әдәбият белгече, язучы**

# МИЛЛИ МУЗЫКА САГЫНДА



Музыка белгече, профессор, фольклорчы галим, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, сугыш ветераны Мәхмүт Нигъмәтҗановка 90 яшь тулды.

Мәхмүт ага Нигъмәтҗанов – тере тарих. Татар музыкасы тарихын аннан да күбрәк белүче юктыр. Ул татар җыр сәнгатенә багышлаган дистәгә якын китап авторы. Аның хезмәтләрендә татар музыкасының фәлсәфи, иҗтимагый тормыш белән бергә үрелеп барган юлы күрсәтелгән, алар чын сәнгатебезнең үсешенә битараф булмаган кешеләр өчен якты маяк булып тора.

Мәхмүт Нигъмәтҗанов – татар халык көйләрен өйрәнүгә гомерләрен багышлаган Солтан Габәши, Александр Ключарев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи кебек композиторлар башлаган изге эшне дәвам итүче. Ул магнитофон, диктофон, нота дәфтәрләре белән коралланып, илебезнең татарлар яшәгән барлык төбәкләрен гизеп йөргән, халык иҗатын саклаган өлкән буын исән чагында фольклор материалын мөмкин кадәр күбрәк яздырып калырга тырышкан легендар музыка белгече. Мәхмүт ага Нигъмәтҗановның экспедицияләре нәтиҗәсе буларак, халык иҗатын туплаган җыентыклары, күләмле монографик эшләре, дистәләгән фәнни мәкаләләре дөнья күрә. Боларга музыка белгеченең «Композиторы и музыковеды Советского Татарстана» («Татарстан композиторлары һәм музыка белгечләре», 1986) белешмәлеген, «Татарская народная музыка» («Татар халык музыкасы», 2003) һәм башка китапларын өсти алабыз.

Галим, музыка белгече буларак, музыкаль дөньяны аерым дөнья итеп күреп, шул өлкәдә генә кайнамый, ул татар җәмгыятенең рухи кыйбласын күзәтеп, барлап, анализлап, көрәшеп яши. Билгеле ки, сәнгать – тормышыбызның көзгесе. Ул гомере буена теләсә нинди трибунадан үз фикерен әйтә алган, туры сүзле, куркуның һәм ялагайлыкның нәрсә икәнен дә белмәгән батыр йөрәкле шәхес булды.



Мәхмүт Нигъмәтҗанов кызы Айгөл һәм оныгы Камилла белән



Гесләдә уйнаучы – Арча районы Сәрдәбаш авылыннан Сәрби Гаврилова, 1960 ел



Һава Кучумова – борынгы себер татарлары җырларын башкаручы. Тубыл шәһәре, 1982 ел

Күренекле галимнең тәрҗемәи хәленә күз салсак, аны нәкъ менә шулай яшәргә тормыш үзе әзерләгәненә ышанабыз.

Мәхмүт Нигъмәтҗановның балачагы Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Ул тумышы белән Саба якларыннан. 1939 елда әтисе Нигъмәтҗан гаиләсен Донбасс якларына алып китә. «1941 елның июле, без яшәгән шахтерлар шәһәре Кадиевкадан эшкә яраклы бар халык та эвакуацияләнгән, – диеп искә ала ул. – Миңа ул чакта 11 яшь. Авыру әнием бик авыр хәлдә хастаханәдә ята. Янына барсам, палатада әнидән башка беркем дә калмаган, медперсонал да эвакуацияләнгән. Танышларны табып, әнине өйгә алып кайттым. Бер-ике көннән шәһәргә Германия гаскәрләре басып керде. Танышлар белән әнине җирләп куйдык».

«Әнием бик дини, догалар белә, гарәп язмаларын оста укый иде. Миңа авыр хәлләрдән чыгарга мәрхүм әниемнең рухы булыша кебек тоела иде», – ди ул.

Балачагы сугыш һәм сугыштан соңгы елларга туры килгән егетнең характеры чын көрәшче булып формалаша. Профессиональ сәнгать юлына да юллары урау була. Юдино тимер юллар белгечләре әзерләү училищесын тәмамлап, поезд машинисты булып эшләвен дә сагынып искә ала ул.

Мәхмүт Нигъмәтҗанов Казан консерваториясенә тормышны белеп, музыка өлкәсендә дә багажын баетып, өлгергән шәхес булып килеп керә. Шуңа күрәдер дә профессиональ музыка баскычларына баскан беренче көненнән үк сәнгатькә формаль караган, очраклы кешеләргә карата бик катгый позиция ала һәм гомер буена шул карашына тугры булып кала.

Консерваториядән соң музыка училищесында укыта. Аннары Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәре буларак (1960-1967, 1974-1984 еллар), татар фольклоры буенча экспедицияләргә йөри башлый. 1967-1973 елларда Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе була. 1984-2003 елларда – Казан педагогика университетының татар музыкасы һәм халык музыка уен кораллары кафедрасы мөдире.

Галимнең татар музыкасы өлкәсендә беренче гыйльми эзләнүләре 1964 елда басылып чыккан «Татарская народная песня в обработке композиторов» җыентыгыннан башланып киткән. Мәхмүт Нигъмәтҗановның беренче җыентыгыннан ук бер фикере ассызыклана – композиторның иҗаты бары тик халык иҗатына гына таянырга тиеш, шул чакта гына ул музыка милли үзенчәлеген югалтмаячак. Шунысы игътибарга лаек: галим гомере буе бу фикеренә тугры булып кала, аның музыка өлкәсендәге фәнни тикшеренүләре шушы юнәлештә дәвам итә. Ул гыйльми эшләрендә халык иҗатын шул төбәктә яшәүчеләрнең тарихына, яшәү рәвешенә, табигатенә бәйләп карый. Шул ук вакытта ул аларны татар музыка культурасы кысаларында сурәтли.

Мәхмүт Нигъмәтҗановның эшчәнлеге фәнни кыйммәткә генә түгел, практик яктан



Эстрада сәнгате студиясе чыгарылышы белән Мәскәүдә (1968-1970). 2010 ел

да зур әһәмияткә ия. Аның хезмәтләре татар җырчыларын да, Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле репертуарын да баетты. Татар эстрадасында популярлашкан «Олы юлның тузаны», «Чатырлар» кебек татар халык җырлары нәкъ Мәхмүт ага Нигъмәтҗановның хезмәте нәтиҗәсе – ул аларны халык теленнән язып алып, эшкәртеп, җырчыларга тапшырды.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе булып эшләгән дәвердә Мәхмүт Нигъмәтҗанов татар җыр сәнгатен профессиональ яктан күтәрүгә зур өлеш кертә. Мәскәүдә Бөтенроссия эстрада сәнгате студиясе ачылгач, татарча яхшы белгән татар яшьләрен сайлап алып, Мәскәүгә укырга илтеп куючы да ул була. 14 талантлы яшь кеше арасында Зиннур Нурмөхәммәтов, Рабига Сибгатуллина, Клара Хәйретдинова, Римма Ибраһимовалар була. Шулай итеп, Мәхмүт ага тырышлыгы нәтиҗәсендә филармония профессиональ кадрлар белән тәэмин ителә.

Шәхеснең татар музыка тарихына хөрмәтенең ни дәрәҗәдә зур булуына бер генә мисал: татар профессиональ музыка сәнгатенең чишмә башында торган Салих Сәйдәшев һәм Солтан Габәшиләрнең туган ягында – Дөбъязда музыка мәктәбен ачуны да ул оештырып йөри.

Сәнгатебезнең күбрәге күңел ачу чараларына корылган чорда бөтен гомерен татар профессиональ сәнгате һәм аның чын шәхесләренә багышлаган акыл иясенә бүген җиңел түгелдер. Ул әле дә хезмәттә. Татар музыка тарихын фундаменталь язмалар, фольклор материаллары, фәнни этнографик хезмәтләре белән баеткан галимнең 2017 елда «Милләтем чын сәнгатькә лаек» дип аталган зур күләмле хезмәте дөнья күрде. Галимне бүгенниләр борчый – әлеге китапта бу сорауларга җаваплар бар.

**Наилә ЯХИНА,**
**шагыйрә, композитор**

Фоторәсемнәр Мәхмүт НИГЪМӘТҖАНОВның шәхси архивыннан

# Җил, яңгыр һәм башкалар




**Нәрсә ул җил? Ул ничек барлыкка килә? Нинди җилләр була? Аның нинди файдасы һәм зыяны бар?.. Яки нәрсә ул чоңгыл? Сулыкта су коену өчен нинди таләпләр бар? Су коенганда, чоңгылга юлыксаң нишләргә?.. Шушы һәм башка сорауларга җавапларны сез әлеге китаптан укып белә аласыз. Биредә табигать күренешләре белән бәйле сүзләрне дә тулы аңлатмалары белән табарга мөмкин. Мәсәлән, кар чәчәге – умырзая; кар тоту – ясалма каршылыклар тудырып, ачык кырда кар туплау һәм башкалар.**

## ҖИЛ – ҺАВА АГЫМЫНЫҢ ХӘРӘКӘТЕ

### Нинди җилләр була?

*Саба җиле* – иртәнге җиләс, йомшак җил.

*Талгын җил* – тынычкына искән җил. Аны тымызык җил дип тә йөртәләр.

*Көчле җил* – зур тизлеккә ия булган җил. Ул агач яфракларын гына түгел, кешене дә очыртып алып китәргә мөмкин.

*Котып җиле* – төньяктан искән җил. Ул салкын була, урамга юка кием киеп чыксаң, тиз арада кием аша үтә, өшетә.

*Төшлек җиле* – көньяктан искән җил. Гадәттә, ул җылы була.

*Үтәли җил* – бер-берсенә капма-каршы урнашкан ачыклыклар (тәрәзә, ишек, форточка һ. б. булырга мөмкин) аша йөри торган һава агымы.

### Җил ничек барлыкка килә?

Иге-чиге булмаган океаннар һәм диңгезләр, кара урманнар һәм далалар, эссе чүлләр һәм мәңгелек боз катламнары өстендә һава агымы бертуктаусыз хәрәкәт итә. Җылы һава өскә күтәрелә, ә салкын һава аста кала. Шулай итеп, Җир шарында өзлексез һава алмашы бара: һава бер урыннан икенче урынга күчә. Шуннан җил барлыкка килә.

### Сүз эчендә энҗе бар!

Татар телендә «җил» белән бәйле сүзләр бик күп. Кайберләре белән танышыйк.

• *Җил күрсәткеч* – флюгер, җилнең юнәлешен билгели торган махсус прибор.

• *Җил тегермәне* – җил көче ярдәмендә ашлыктан он тарттыра торган махсус корылма. Заманча җил тегермәннәре электр энергиясе алу өчен файдаланыла.

• *Җилгәргеч* – сугылган игенне чүптән аеру өчен авыл хуҗалыгында кулланыла торган җайланма. Ашлыкны әлеге җайланма аша үткәрүне җилгәрү дип атыйлар.

• *Җил капка* – элекке заманнарда такта булмау яки такта җитмәү сәбәпле, агач киртәләрдән ясалган ачылмалы капка.

• *Җилкән* – корабны, йә булмаса көймәне җил көче белән хәрәкәткә китерү өчен мачтага беркетелә торган махсус тыгыз тукыма. Аның читләрен, ертылмасын өчен, аркаҥнар ярдәмендә беркеткәннәр. Җилкән белән идарә итүчене җилкәнче дип йөрткәннәр.



• *Җилләткеч* – бина эчендәге һаваны йөртү өчен уйлап табылган ясалма җил чыгару җайланмасы. Русчасы: вентилятор.

• *Җилпәзә* – җәйгәч ярымтүгәрәк барлыкка китерә торган һәм кул көче ярдәмендә ясалма җил булдыру, җилләтү өчен кулланыла торган җайланма.

• *Җилкуар* – эшсез йөрүче, вакытын бушка, тик йөреп уздыручы кеше.

• *Җил чәчәге* – йогышлы авыру исеме.

• *Җил үлән (дүңгәләк)* – дала һәм чүлдә үсә торган үсемлек. Орлыгы өлгереп җиткәч, сабагы тамырыннан аерыла һәм аны җил тәгәрәтеп йөртә. Русчасы: перекати-поле.

• *Җил-җил (атлау)* – җиңел һәм житез атлау.

• *Җилдертү, җилдерү* – кызу-кызу хәрәкәт итү.

• *Җилпенү* – очарга омтылу, талпынып алу.

• *Җиләс* – салкынча һава, яки бераз гына җил исеп торган, бөркү булмаган урын.

• *Җил алгандай (булу)* – кинәт юкка чыгу.

• *Җил дә тидермәү* – бик нык итеп саклау.

• *Җил койрыгын тотып калу* – алдану, нәрсәгә дә булса өлгерә алмыйча калу.

• *Җил уйнату* – житез хәрәкәтләнү, кызу итеп эшләү.

• *Җилгә очу* – юкка чыгу, әрәм булу.

### Җилнең хуҗасы

Борынгы заманнарда җилне «күренмәс рух» белән чагыштырганнар. Шуңа аны «Җил Тәңресе», «Җилбәгән», «Җил иясе», «Җил анасы», «Җилләр патшасы» дип йөрткәннәр. Татар халкында җилләрнең башлыгы «Ялман» исемле булган, имеш.

### *Җил бакчага кергән...*

*Җил бакчага*
*Кергән.*
*Ал алмалар*
*Күргән.*

*Ботакларга*
*Кунган.*
*Җиргә алма*
*Койган.*

*Этләр өргән*
*Аңа:*
*«Сорамыйча*
*Алма!»*

*Җил капканы*
*Ачкан –*
*Җил-җилаяк*
*Качкан...*

*...Көз буена*
*Җилдән*
*Алма исе*
*Килгән...*

*Шәүкәт Галиев*

## ЯҢГЫР – БОЛЫТЛАРДАН ЯВА ТОРГАН СУ ТАМЧЫЛАРЫ

### Нинди яңгырлар була?

*Ләйсән яңгыр* – язын беренче тапкыр сибәләп яуган вак кына җылы яңгыр.

*Эре яңгыр* – җәйге яңгыр. Гадәттә, каралып, куерып килгән болыттан ява. Авыр, эре яңгыр тамчылары җиргә уктай атыла, тәнгә тисә, салкынлыгы белән чеметеп-чеметеп ала.

*Яшенле яңгыр* җәйге челлә вакытында була. Кап-кара болытлар бергә җыела, һәм көчле җил куба. Яшен яшенли, күк күкри, шул ук вакытта яңгыр да чиләкләп коярга тотына. Яшенле яңгыр вакытында боз да яварга мөмкин.

*Давыллы яңгыр* – көчле җил белән катыш яңгыр.

*Җылы яңгыр, кояшлы яңгыр* – җәй көне ява һәм, гадәттә, кояшлы көнне сибәләп китә.

*Кыска вакытлы яңгыр* – бик аз вакыт эчендә яуган яңгыр.

*Вак яңгыр* – көзге салкын яңгыр. Гадәттә, ул бертуктаусыз сибәләп тора. Тамчылары вак, җиңел була, шуңа алар җиргә дә әкрен генә төшәләр.

Бар дөньяны томалап ява торган вак яңгырны уздырмый торган яңгыр дип тә йөртәләр.

*Кышкы яңгыр* – табигатьтә барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә кыш көне ява торган карлы һәм бозлы яңгыр.

### Яңгыр ничек барлыкка килә?

Кояш диңгез, океан, елга, күл өстен җылыта һәм аларның суын парга әйләндерә. Пар җылы һава агымы белән югарыга күтәрелә. Ул шунда суына, куера һәм бик вак су тамчылары хасил итә. Без аларны ак болытлар итеп күрәбез. Бер-берсе белән кушылып, эреләнгән, авырайган тамчылар исә сибәләп яисә коеп ява торган яңгыр булып җиргә төшә.

Яңгыр менә шулай барлыкка килә.

### Сүз эчендә энҗе бар!

• *Яңгыр башмагы* – өлгергәннән соң кара-кучкыл тузанга әйләнә торган шарсыман гөмбә, «аю тәмәкесе». Русчасы: дождевик.

• *Яңгыр суалчаны* – туфракта яши һәм яңгырдан соң җир өстенә чыга торган корт.

• *Яңгыр үлчәгеч* – яуган яңгырның күләмен үлчи торган прибор.

• *Йолдызлар яңгыры* – төнлә җиргә яуган вак метеоритларны яңгырга охшатып әйтү.

• *Яңгырлау* – бик еш яңгыр яву.

• *Яңгыр күзе төшү* – яңгыр явар алдыннан, берәм-сәрәм тамчы тамып алу.

• *Яңгырдан соң чыккан гөмбәдәй* – бик тиз, бик күп булып барлыкка килү.

### Яңгыр ялкауларны билгели

Татар халкында бер кызык гыйбарә бар. Яңгыр явар алдыннан, беренче тамчы кемгә төшә, шул кеше ялкау булып санала.

### 100 сорау

Яңгыр боткасы буламы?

Була икән шул. Элекке заманнарда, озак вакыт яңгыр яумый торган корылыклы елларда, балалар өй саен тоз, май, ярма җыеп йөргәннәр. Аннары, су буена төшеп, казан асып, тәмле ботка пешергәннәр. Су сибешеп уйнаганнар.

*Яңгыркаем, яу, яу!*
*Майлы ботка бирермен.*
*Майлы ботка казанда,*
*Тәти кашык базарда!.. –*
*дип, яңгыр чакырганнар.*

Үзең дә эссе көндә су сибеп уйнап, такмак әйтеп, яңгыр чакырып кара әле. Ничек барып чыгар икән?..

### Нәрсә ул яңгыр намазы?

Көчле корылык булган елларда әби-бабайларыбыз, кырга чыгып, Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сорап, намаз укыганнар. Корбан да чалганнар. Шул яңгыр намазы дип аталган.

### Яңгырның алиһәсе, яңгыр иясе булганмы?

Әле ислам дине барлыкка килгәнче үк, борынгы гарәп мифларында күк һәм яңгыр алиһәсе булган, имеш. Аны әл-Лут яки әл-Лат дип атаганнар.

Төркиләрдә дә яңгыр Тәңресе булган. Аны «Бәркет-баба», «Бәркет-дивана» дип тә йөрткәннәр. Татарлар исә аны гади генә итеп, «Яңгыр иясе» дип атаганнар.

### *Яңгыр ява*

*Яңгыр ява! Яңгыр ява*
*Шыбыр-шыбыр.*
*Йөгереп чыга бала-чага,*
*Ыбыр-чыбыр.*

*Яшен яшьни, күкләр тетри*
*Дөбер-шатыр!*
*Курыкмыйлар, кулларында*
*Зонтик-чатыр.*

*Кар өстендә йөргән чакта*
*Шыгыр-шыгыр,*
*Искә төшәр яуган яңгыр*
*Шыбыр-шыбыр.*

*Бер җүнсезе сукырана*
*Мыгыр-мыгыр.*
*Аңламый ул: шатлык ява*
*Шыбыр-шыбыр.*

*Илдар Юзеев*

**Наилә ЗЫЯТДИНОВА әзерләде,**
**Татарстан китап нәшрияты хезмәткәре**

Табигать күренешләре энциклопедиясе / Ленар Шәех. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 96 б.

# УЕН – халык мәдәниятенең бер күренеше

**(Яңа Чишмә районы Акбүре авылында узган фольклор-этнографик экспедиция материалларыннан)**



Уен баланың физик тәрбиясендә һәм әхлакый үсешендә аерым урын тота. Фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт уенны балалар өчен «иҗтимагый дәрес» дип билгеләгән. Уен барышында баланың аралашу һәм җәмгыятьтә яшәү тәҗрибәсе булдырыла. Бала уен аша әти-әнисе, әби-бабасы, апа-абыйлары белән, соңрак яшьтәшләре белән аралашу тәҗрибәсе туплый, бер-беренә юл куярга, көндәлек проблемаларны хәл итәргә өйрәнә.

Күмәк уеннар гадәттә санавычлардан башлана: «көтүче» (уенны алып баручы) билгеләнә.

Санавычлар арасында ниндидер бер гомуми мәгънәгә ия текстлар аз, алар нигездә стилистик рифмага корылган сүзләр җыелмасыннан тора. Мәсәлән, экспедиция вакытында мондый санавычлар язып алынды:

*Ыргадан, мыргадан*
*Мәче йөри елгадан.*
*Карга-чыпчык,*
*Умырып-чумырып,*
*Син кал, бу чык.*

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, татар уеннарының барысы да диярлек балалардан акыл һәм иҗади якын килүне таләп итә, еш кына тормышта кирәк булачак хәрәкәтләргә яки осталыкка өйрәтүне үз эченә ала. Балалар уеннары милли мирасны ныгыту өчен нигез формалаштыру һәм тәрбия чарасы булып тора.



«Туганай» фольклор ансамбленең катнашучылары

«Буяу сатам», «Көйле-таяк уены», «Керәшле уен», «Аю – бүре», «Бакыр бүкән» уеннары үсеп килүче буыннан җитезлек һәм зирәклек, тапкырлык таләп итә. Шул ук вакытта, туган телне өйрәнү, тел байлыгын үстерү ягыннан да әһәмияте зур.

Экспедиция вакытында язып алынган кайбер уеннар белән таныштырып китәбез. Алар Яңа Чишмә районы Акбүре авылында яшәүче Васил Вәлиҗан улы Вәлиуллиннан (1974 елгы) язып алынды. Васил Вәлиуллин – Акбүре авылы урта мәктәбенең тарих укытучысы һәм мәктәп музее директоры. Ул халык уеннары белән кызыксынып, аларны туплап, балаларга өйрәтә – халык мәдәниятенең бу күренешен саклап калуга зур өлеш кертә.

### Алам-алам бакчакүз

Бу уен болында уйнала. Уенда кимендә 6-7 бала катнаша. Башта «әби»не билгеләү өчен шобага салына, яисә ул санашу юлы белән ачыклана. Уенчылар бер рәткә тезелеп баса. Уртада «әби» «чокыр» казый.

– Әби нәрсә казыйсың?

– Алтын энә казыймын.

– Алтын энә нәрсәгә?

– Капчык тегәргә?

– Капчык сиңа нәрсәгә?

– Синең балаларыңны бәреп-бәреп куарга.

Шуннан соң тезелеп баскан балалар сибелешеп чабалар, «әби» алар артыннан куа. Тотылган балалар «чокыр» тирәли җыела. Уен соңгы уйнаучыны тотып бетергәнче бара. Иң беренче тотылганы икенче уенда «әби» була.

### Дүртпочмак

Бу уенда 5 бала катнаша. Аны агач бура эчендә уйныйлар. Элегрәк, куркынычсызлык кагыйдәләрен бозып, трактор арбасы өстендә, бик тә экстрим яратучылары трактор барган вакытта уйнаган. Чөнки бу чорда балаларның физиологик үсешендә барган үзенчәлекләр аларны тәвәккәл булырга һәм бернәрсәдән дә курыкмаска этәрә. Гадәттә бу уенны малайлар уйный.

Бура эчендә 4 кеше дүрт почмакка баса, берсе көтүче булып уртада кала. Балалар бер-берсе белән урыннарын алыштырып, почмактан почмакка чабышалар. Алар ян-яклап та, диагональ буенча да хәрәкәт итә ала. Көтүче уенчылар алмашынган арада, буш почмакка кереп калырга тырыша. Урынсыз калганы көтүче була.

## БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...













### «Без-без» уены

Балалар баш бармакларын тотышып утыралар, шуның белән «Зур куллар баганасы» ясала. Кулларын өскә-аска селкетеп, җырлыйлар: «Без, без, без идек, без унике кыз идек, базга төштек – май ашадык, келәткә кердек – бал каптык, бер тактага тезелдек, таң атканчы юк булдык».

– Май кайда?
– Тычкан ашаган.
– Тычкан кайда?
– Салам астында.
– Салам кайда?
– Үгез ашаган.
– Үгез кайда?
– Елгага баткан.

Җырлап бетереп, «Авызыңа кап та йом» дигәч, бөтен уйнаучы бала авызын йома. Тешләрне күрсәтергә ярамый. Һәр уйнаучы теләсә нинди кыяфәткә кереп, бер-берсен көлдерергә тырыша. Тешен беренче күрсәткән балага җәза бирелә.

### Котылыш

Уенда балалар саны күбрәк булган саен кызыграк. Уенчылар парлашып, кулга-кул тотынышып тезелеп басалар. Уртада бер бала ялгызы кала. Ул – котүче. Парлар кулларын бер-береннән ычкындырып чабалар, ә уртадагы котүче пардагы баланың берсен тотып алырга тырыша. Ул, парлар урыннарына басып, кулларына тотынышканчы, берсен дә тота алмаса, кабаттан котүче булып кала. Берәрсен эләктерсә, тотылган кеше урынына, аның пары белән баса. Тотылганы котүче була. Шул рәвешле уен дәвам итә.

### Бишташ

Сары балчыкны әвәләп, киптереп, биш данә «таш» ясыйлар. Аларны бер-берсенә тими торган итеп, сибеп җибәрәләр дә, чүпләп алалар. Икешәрләп уйныйлар. Башта бер ташны һавага чөяләр, ул төшкәнче, җирдән тагын бер ташны алып, шул ук кул белән төшеп килгән ташны да тотып өлгерәләр. Бу этапны үткәч, икенчесенә күчәләр. Берьюлы икешәр ташны кулга алалар, өчне, һәм калган дүрт ташны берьюлы кулга алып, һавага чөйгән ташны тоталар. Уенны сул кул белән генә уйныйлар, уң кул белән ярдәм итәргә ярамый. Биш ташны да шулай итеп атып-тотып бетергәч, өченче этапка күчәләр. Бу этапта, сул кулның баш һәм имән бармакларын келәмгә бастырып, капка ясыйлар. Таралып яткан ташлар арасыннан берсен алып чөеп җибәрәләр, ул төшкән арада, келәмдә яткан ташның икенчесен алып капкага кертәләр. Тагын бер ташны югары сикертеп, ул төшкәнче ике, өч, дүрт ташны алалар да капкага кертәләр. Капканың торышын үзгәртү катгый тыела. Уен һәр яңа этабында шулай катлаулана бара.

**Сәвия СӘМИТОВА,**
**филология фәннәре кандидаты**

«Әйлән-бәйлән» Татарстан халыклары милли уеннары балалар республика фестиваленнән күренешләр. 2019 ел

# Кич утырып тыңладым...

(Әкият)

Борынгы заманнарда түгел, дәү әнием кыз чакта, дәү әтием егет чакта Сабантуйлар бик күңелле узган. Сабан туе ул – чәчү беткәч, туй үткәрү кебек булган. Халык бу бәйрәмне ел буе көткән. Атна-ун көн кала өйләр юылган, каралты-кура, йорт тирәсе тәртипкә китерелгән.

Бәйрәмгә бүләк, йомырка җыю йоласы – аның башлану билгесе булып торган. Иртәгә Сабантуй дигән көнне оештырылган ул. Бу чарада бөтен авыл халкы уен-көлке, җырбиюләр белән катнашкан. Сабантуйга дип, ераклардан төп нигезләренә туганнар, уллар-кызлар җыелышкан. Милли ризыклардан мул табын әзерләнгән.

Бәйрәм, гадәттә, урман аланында яисә су буенда үткәрелә торган булган. Сабантуйга матур итеп җигелгән атларга утырып барганнар. Халык уеннарда бик теләп катнашкан: кемдер капчык киеп йөгергән, кемдер чүлмәк ваткан, теләгәннәр рәхәтләнеп капчыклар белән сугышкан. Йомырка салынган кашык кабып йөгерү, колгага менеп әтәч алып төшү, көянтә-чиләк белән су ташу кебек уеннарда үзеңнең җитез, кыю, уңган икәнеңне күрсәтергә кирәк булган.

Катыклы савыттан авыз белән акча эзләү, чүлмәк вату уеннары каян чыккан? Беләсезме? Бу турыда дәү әтием менә нәрсәләр сөйләде.

Сабан туе барган вакытта саран авыл баеның көмеш тәңкәсе ялгыш чүлмәктәге катыкка төшеп китә. Бөтен кеше алдында кулын катыкка тыгарга ояла ул. Чүлмәкне авыштырып, тәңкәне авызы белән эзләргә керешә. Әлбәттә, таба алмый, әмма бөтен бите, башы катыкка буялып бетә. Кешеләр, аның кыяфәтен күреп, көлә башлыйлар. Ачуы чыккан бай, кул астындагы таягын алып, чүлмәккә китереп суга. Менә шуннан Сабантуйда бөтен кеше яратып уйный торган уеннар уйнала башлый. Бу уеннар авыл җырчыларының, биючеләренең чыгышлары белән чиратлаштырып алып барылган. Бәйрәмнән беркем дә бүләксез китмәгән.



Екатерина ЖИЛЬЦОВА (11 яшь) рәсеме,
Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы

Әлбәттә, Сабан туенда иң кызу урын – көрәш мәйданы булган. Кечерәк яшьтәге малайларны, көч сынашырга теләк белдергән бабайларны аерым көрәштергәннәр, бүләкләр биреп, мәйданнан хөрмәтләп озатканнар.

Сабантуйда егетләр һәм кызлар үзләренә булачак тормыш иптәше дә күзләгәннәр. Чөнки монда уңганлыкны, булганлыкны, җитезлекне, шул ук вакытта тыйнаклыкны да күрергә мөмкин булган.

Миңа дәү әнием белән дәү әтием сөйләгәннәр шулар. Сез дә, дуслар, алар янында ешрак булыгыз, кичләрен яннарында утырып, куеннарына сыенып, аларны тыңлагыз.

**Эльвира ВӘЛИУЛЛИНА,**
**Яшел Үзән, С.К. Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясенең 4 нче «А» сыйныфы укучысы**

# МАТУР БӘЙРӘМ – САБАНТУЙ!

Җәйләр җитеп, эшләр беткәч,
Бездә була Сабантуй!
Бар халык мәйданга килә –
Күңелләрдә якты уй!

Җыелыша яше-карты
Күрергә, дип тамаша.
Матур итеп киенгәннәр –
Карап күзләр камаша.

Табигатьнең ямьле җире
Үзенә бүген дәшә.
Дус-туганнар, сыйныфташлар
Сагынышып күрешә.

Читтән авылдашлар кайта
Туган ягын сагынып.
Бар да уенда катнаша,
Тормыйлар ялындырып.

Ә уеннар кыза бара –
Кемдер капчыкта чаба.
Йомырка салып кашыкка
Оча бүләккә таба.

Чүлмәк вата япь-яшь кызлар,
Күзләр күрми – бәйләнгән.
Туп-туры сугар иде дә,
Булмый шул – баш әйләнгән.

Кашык белән су ташыйлар
Мәйданның уң ягында.
Капчык сугышын карыйлар
Агайлар сул ягында.

Кара-кара, баганага
Бер малай менеп бара!
Халык аңына килгәнче
Бүләген сүтеп ала.

Келәм уртасында көрәш
Кызганнан-кыза бара.
«Атлар кайта», – дигән тавыш
Бөтен мәйданны яра.

Җыр-биюләр, уен-көлке
Көне буена җитә.
Күңел ачып, сөенешеп
Халык өенә китә.

Сабантуйда балалар да,
Олылар да ял итә.
Кыскасы, килегез, бездә
Сабантуйлар шәп үтә!

**Нәзилә ИБРАҺИМОВА,**
**Минзәлә шәһәрендәге гимназиянең 9 нчы сыйныф укучысы**



**Полина ОСТРОУМОВА (14 яшь) рәсеме, Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы**



**Рената ШАКИРОВА (11 яшь) рәсеме, Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы**

# БӘХЕТ-ШАТЛЫК алып килсен

Сабантуй бик матур бәйрәм –
Ел да көтеп алабыз.
Барлык уенга катнашып,
Сөенеп кул чабабыз.

Берәү җырлый, берәү бии,
Кемдер гармун уйната.
Яшь егетләр көрәшәләр,
Берәүләр чүлмәк вата.

Без бит авыл балалары
Атларны яратабыз.
Алар килә очып-очып,
Аларга җан атабыз.

Безнең Сабантуй урыны
Бик тә матур урында.
Ул күлләре, чишмәләре!
Кошлар сайрый болында.

Бәхет-шатлык алып килсен,
Һәр ел Сабантуйлары!
Тынычлыгыбызны саклый,
Илнең батыр уллары.

**Нәргизә ХӘМИТОВА,
Саба, Юлбат төп мәктәбенең
2 нче сыйныф укучысы**

# Онытылмасын берүк

Безнең авыл Сабан туе
Бик тә күңелле үтә.
Андагы кызыклы хәлләр
Күңелгә үтеп керә.

Гармун белән яшь егетләр,
Яулык җыярга чыга.
Батыр калган, җиңгәннәргә
Бүләкләр бик күп була!

Сабантуйга дип, ерактан,
Күп туганнар кайталар.
«Әле ярый бәйрәм бар», – ди,
Абыйлар  һәм апалар.

Уеннар нинди кызыклы:
Капчык сугышы, узышлар,
Катыктан акча эзләүләр,
Көрәш, бию һәм җырлар!

Онытылмасын иде бер дә,
Мондый күңелле бәйрәм!
Дуслаштыра барыбызны –
Көтәбез гаилә белән!

**Камилә ШАКИРОВА,**
**Яшел Үзән, С.К. Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясенең 4 нче «А» сыйныфы укучысы**



**Софья РОМАШЕВА (13 яшь) рәсеме, Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы**

# ЧИГҮ ОСТАСЫ

Нурзия Мирхазова сүзләре

Наилә Яхина көе




Калфак чигәм, энҗе тезәм,
Кичләр буе утырып.
Песиебез карап тора
Миңа, күзен тутырып.
    Лә-лә-лә лә-лә-лә,
    Миңа, күзен тутырып.
Әни бәйли, ә мин чигәм,
Бирелеп уй-хисләргә.
Киңәшләшәм әни белән,
Белмәсәм ни эшләргә.
    Лә-лә-лә лә-лә-лә,
    Белмәсәм ни эшләргә.
Ялгыштырды мине менә
Кара мәчем – Акмуен,
Әллә ул карагангамы,
Чуалып китте уем.
    Лә-лә-лә лә-лә-лә,
    Чуалып китте уем.
Башым күккә тиде, әни
«Афәрин, кызым» – дигәч,
Курчагым да зур кыз булды,
Чигүле калфак кигәч.
    Лә-лә-лә лә-лә-лә,
    Чигүле калфак кигәч.



**Шәмәхә тестәге калфак. XIX гасыр азагы.
Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать дәүләт музее фондларыннан**

# Татлы бәлеш



**Аксубай якларында бәйрәм табыны оста хуҗабикәләр пешергән тәмле ризыклардан сыгылып тора. Шундый хуҗабикәләрнең берсе – Халисә Нуртдин кызы Мөхәммәдиева журнал укучыларыбызны Аксубай якларында гына очрый торган «Татлы бәлеш» пешерергә өрәтә.**

***Бәлеш камыры өчен:***

*200 мл сөт,*
*1 аш кашыгы көнбагыш мае,*
*2 аш кашыгы майонез,*
*кашык очы белән тоз,*
*йомшак камыр килеп чыгарлык он.*

***Бәлеш эчлеге өчен:***

*1,5 стакан дөге (тозлы суда бүрттерәбез, юабыз һәм сөлгегә җәеп кипшендерәбез),*
*1 стакан карабодай ярмасы (кайнар су салып, өстен томалап, бүрттерәбез),*
*200 грамм йөзем,*
*200 грамм кара җимеш,*
*200 грамм сары җимеш (бүрттерәбез),*
*400 грамм сары май (эретәбез),*
*150 грамм шикәр комы.*

***Татарларның, дөресрәге, болгарларның ничек туклануы турында иң борынгы язмаларның берсен Багдад хәлифенең Алмыш хан янына сәяхәт иткән сәркәтибе Ибн Фадлан язып калдырган (922 елда Идел Болгарының исламны кабул иткән вакытлары).***

«Бер-ике сәгатьтән Болгар ханы безне алырга кешеләр җибәрде, һәм без аның янына чатырга кердек. ...Ул сыйлы өстәл китерергә боерды, аңа өстәл китерелде. Өстәлдә кыздырылган ит кенә тора иде.



Ул, пычак алып, ит кисәге кисеп алды да кабып җибәрде. Шулай ук икенче, өченче кисәкләрне ашады. Аннары бер кисәк кисеп, хәлиф илчесе Сусан ар-Рассига бирде. Шул вакыт кечкенә өстәл чыгарып илче алдына куйдылар. Тәртибе шундый: хан үзе кисеп бирми торып, беркем дә ризыкка сузылмый. Ризык бирелгән кешегә шул мизгелдә өстәл куела.
...Һәрберсе дә уртак өстәлгә сузылмыйча, үз өстәлендә ашады. Беркем дә патша өстәленә кагылмады.

Патша ашап бетергәч, һәрберебез өстәлдә калган ризыгын үзе белән алды. Ашаганнан соң патша бал эчемлеге китерергә боерды. Эчемлекнең яңа гына әзерләнгәне сизелеп тора иде...»

Әнвәр Хәйри (Әнвәр Нәҗип улы Хәйруллин). Әхмәд ибне Фадланның 921-922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе (татар теленә яңача тәрҗемә һәм фәнни аңлатмалар). – Казан: «Сүз» нәшр., 2013, 536 б., рәсем белән



*1. Йомшак кына камыр басабыз һәм аны ике өлешкә бүләбез*



*2. Табаны канат белән майлыйбыз. Камырның зуррак өлешеннән бәлеш төбе ясап, табага җәябез*



*3. Бәлеш эчлеген кушып, камыр өстенә җәеп салабыз*



*4. Өстенә эреткән май сибәбез*



*5. Камырның икенче өлешен җәеп, бәлеш өстенә каплыйбыз*



*6. Кайнар газ мичене куеп, 160-200 градуста 40 минут пешерәбез*

***Ашларыгыз тәмле булсын!***

Әлфия НУРХАМӘТОВА
фоторәсемнәре

# ШАХВОРД

Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән шахмат фигураларының ферзь һәм ат йөреше тәртибен кулланып, Сабантуй ярышларының исемнәрен укыгыз.

Шахмат фигуралары (ферзь һәм ат) журнал укучыларын уйларга, дөрес йөрергә, язарга өйрәтә.

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| а | | ш | ә | ы |  | К | һ | л |
| ы | р | р | а | у | ш | ү | з | ә |
| | л | в | т | ш | Җ | ә | н | р |
| ө | б | к | ы | ы | р | ы | е | б |
| | ә | р | | | ы | ч | м | ә |
| а | К | м | я | р | а | л | л | й |
| ү | л | ч | ә | е | б | а | п | ә |
|  | ч | н | л | т | к | я | а | т |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17 | | 15 | 4 | 19 |  | 1 | 6 | 4 |
| 14 | 3 | 18 | 31 | 33 | 5 | 2 | 3 | 5 |
| | 16 | 30 | 32 | 45 | 34 | 7 | 7 | 6 |
| 2 | 13 | 29 | 44 | 46 | 36 | 35 | 8 | 9 |
| | 28 | 43 | | | 38 | 37 | 8 | 10 |
| 12 | 1 | 27 | 42 | 41 | 40 | 39 | 12 | 11 |
| | 26 | 11 | 22 | 20 | 18 | 9 | 14 | 13 |
|  | 24 | 23 | 21 | 10 | 19 | 17 | 16 | 15 |

**Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде**

Башваткыч җаваплары:
Дөрес ат йөреше тәртибе: саннарда – 1-19
Хәрефләрдә: көрәш һәм ат чабышлары
Дөрес ферзь йөреше тәртибе: саннарда – 1-33
Хәрефләрдә: күзләрне бәйләп таяк белән чүлмәк вату; җырлап ярышы

# Истәлекле һәм онытылмас даталар
# 2020

**1 июль**

Язучы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Камил Әдһәм улы Кәримовка 70 яшь (1950)

**4 июль**

Җырчы, ТАССРның атказанган артисты Зифа Җәмил кызы Басыйрованың тууына 110 ел (1910-1979)

**5 июль**

Композитор, җырчы, мәдәният эшлеклесе, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Мәсгут Габдрахман улы Имашевка 90 яшь (1930)

**7 июль**

Композитор, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әнвәр Закир улы Бакировның тууына 100 ел (1920-2001)

**15 июль**

Җырчы, Татарстанның халык артисты, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Римма Мөбарәк кызы Ибраһимовага 70 яшь (1950)

**27 июль**

Сынчы, Татарстан Республикасының халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Мәхмүт Маталит улы Гасыймовка 75 яшь (1945)

**28 июль**

Сәнгать белгече, шагыйрә, тәрҗемәче, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Розалина Гомәр кызы Шаһиевага 75 яшь (1945)

**1 август**

Татар һәм башкорт әдәбиятлары классик язучысы – шагыйрь, прозаик, публицист һәм драматург, Башкортстан АССРның халык язучысы Мәҗит Гафуриның тууына 140 ел (1880-1934)

**1 август**

Тел галиме, ТАССРның һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, Татарстан фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фуат Әшрәфҗан улы Ганиевнең тууына 90 ел (1930-2016)

**3 август**

Хор дирижёры, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең халык артисты Лима Гали кызы Кустабаевага 75 яшь (1945)

**5 август**

Актриса, Татарстан Республикасының халык артисты Наилә Нургазиз кызы Ибраһимовага 75 яшь (1945)

**10 август**

Алабуга, Арча, Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Лениногорск, Мамадыш, Минзәлә, Октябрь, Питрәч, Саба, Сарман, Спас, Тәтеш, Тукай, Чистай районнары оештырылуга 90 ел (1930)

**11 август**

Язучы, драматург, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Зөлфәт Зөфәр улы Хәкимгә (Хәкимхановка) 60 яшь (1960)

**15 август**

Рәссам Ильяс Шәйхулла улы Фәйзуллинга 70 яшь (1950)

**19 август**

Пианист, органчы, педагог, Татарстанның халык артисты, Россия Федерациясенең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Кәбир улы Абдуллинга 70 яшь (1950)

**23 август**

Язучы Марат Рафил улы Кәбировка 50 яшь (1970)

**25 август**

Драматург, җәмәгать эшлеклесе, ТАССР, РСФСР, Башкортстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның К.С. Станиславский, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты Туфан Габдулла улы Миңнуллинның тууына 85 ел (1935-2013)

**28 август**

График, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Алсу Адлер кызы Тимергалинага 60 яшь (1960)

**30 август**

Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителүгә 30 ел (1990)

**12 сентябрь**

Журналист, архивчы, ТАССРның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты Дамир Рәүф улы Шәрәфетдиновның тууына 80 ел (1940-2014)

**12 сентябрь**

Чистай шәһәрендә Борис Пастернакның Мемориаль музее ачылуга 30 ел (1990)

**13 сентябрь**

220 ел элек Казанда беренче татар типографиясе ачыла (1800)

**15 сентябрь**

Драматург, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Таҗи Кәлимулла улы Гыйззәт (Гыйззәтуллин) нең тууына 125 ел (1895-1955)

(Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре = Календарь знаменательных и памятных дат. 2020 – Казан: Милли китап, 2019. – 200 б.)








Кадерле укучыларыбыз!
2020 елның икенче
яртыеллыгы өчен «Түгәрәк
уен» альманахына
республикабызның барлык
элемтә бүлекләрендә
язылырга мөмкин.
Яисә иң җиңел ысулы – өйдән чыкмыйча гына
«Почта России» сайты аша (https://podpiska.
pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип
җыярга) онлайн да языла аласыз.

Индексыбыз – ПА 183
Өч айга язылу бәясе – 173 сум 29 тиен
Ярты елга язылу бәясе – 346 сум 58 тиен

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!